«Безнең тарих чит ил туристларының акылына сыймый»

Гадәттә, Казанны Россиянең өченче туристлык башкаласы, диләр. Ләкин аннан тыш та республикабызда Алабуга, Болгар, Зөя утрау-шәһәрчеге, Чистай кебек популяр туристлык үзәкләре бар бит әле. Сәяхәтләр сезоны ачылган вакытта бу үзәкләрнең берсе – Болгар шәһәрен сынап карадык.

7 БИТ

Туфан туган туфракта

Кырлай, Сыркыды, Иске Кирәмәт, Күлле Киме… Татар әдипләрен дөньяга биргән шагыйранә исемле бу авыллар арасында Олы Мәрәтхуҗаның да аерым бер урыны бар. Танылган драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның туган авылы. Туфан абыйның кызы Әлфия ханым Миңнуллина һәм хатыны Нәҗибә апа Ихсанова чакыруы буенча без – бер төркем каләм әһелләре, дуслары – 1 май иртәсендә Кама Тамагы районына кузгалдык.

9 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри Казан

татмедиа

Җомга | 5.05.2017 | № 48 (5810)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

Евгения Маслова:

«СУГЫШЧЫЛАРНЫҢ ЯРДӘМ СОРАП ЯЛВАРУЛАРЫН ӘЛЕ ДӘ ИШЕТӘМ КҮК»

Кулымдагы фотодан елмаеп карап торучы хәрби киемдәге яшь кызны бүген сугыш ветераны Евгения Маслова дип уйламассың да. Хәер, көләч, куе коңгырт күзләр шул ук. 99 яшендә булса да, Евгения Яковлевна әле дә төс ташламаган: мөлаем, ачык, аралашучан. Безне дә, килүгә, үбеп, кочып алды. Сугыш вакытында иң «кайнар нокта»ларда булган ветеран Җиңү көне алдыннан сугышчан хатирәләре белән урталашты.

Эльвира МОЗАФФАР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Казан дәүләт институты каршындагы Шәфкать туташлары мәктәбен тәмамлауга ук фронтка җибәргәннәр. Аның сугышта күргәннәрен газета битләренә генә язып бетерерлек түгел. Күбесен инде хәтерләп тә бетерми ветеран. Кайберләрен сөйләгәндә, үзе дә: «Ул авырлыкларга ничек түздем икән?» – дип гаҗәпләнә. Дошман кырына эләккәч, кача-поса ун чакрымлап, үзебезнекеләр ягына чыгу, сугышчан дуслары белән чолганышта калу, контузия алу, яралы солдатлар, яшәү белән үлем арасында тартышу – кызлары һәр истәлекне теркәп бара.

– Минем бурыч яралы солдатлар өчен хәрби госпиталь булдыру иде. Авыруларны дәвалар өчен бина табарга кирәк булды. Көч-хәл белән бер сарайның ишегеН ачып кердем. Кап-караңгы. Бинаның диварларын капшый башлагач, курып калдым. Стена буйлап мәетләр өелгән. Ләкин коелып төшәргә ярамый. Бүлмәне чистартып, солдатларны шунда дәваладык, – дип искә ала әңгәмәдәшем. Ул чакта аңа нибары 24 яшь булган.

Хәрби госпитальләрдә иң авыр шартларда эшләргә туры килә. Берсендә операция вакытында дошман ут ача. Бина түшәменнән штукатур коела. Ут юк. Күрше-тирәдә йортлар яна. Әмма операцияне өзәргә ярамый. Яралы солдат үләргә мөмкин. Керосин лампасы яктысында, авыруны брезент плащ-чатыр белән каплап, операцияне дәвам итәләр. Солдат, тернәкләнү узып, фронтка кайта. Өлкән шәфкать туташы бик күп солдатларны үлем ятьмәсеннән йолып кала.

Бер вакыйга аеруча истә калган.

– Туфрак арасыннан күренеп торган шинель кисәген тарта башладым. Ул атыш вакытында күмелеп калган солдат булып чыкты. Исән. Тиз арада операция ясап, егетне коткардык. Аннан соң да озак яшәде әле ул. Миңа гел рәхмәт әйтә иде, – дип искә ала Евгения ханым.

→ Ахыры 2нче биттә.

БӘЙРӘМ ЧАРАЛАРЫ

«Үлемсез полк» йөрешеннән тыш та, **9 Май** көнне башкалада бик күп чаралар уздырыла. Казан ветераннарын шәһәрнең һәр районында котлаячаклар. Алар белән очрашулар узачак, концертлар куелачак. Шәһәрнең һәр районында ачык һавада күңел ачу чаралары узачак. Шулай ук барлык ветераннарга түләүсез медицина күзәтүе оештырыла, ялгызларның фатирларын ремонтлаячаклар. 9 Май көнне **08.00 сәгатьтә** Арча зиратында республика җитәкчеләре катнашында тантаналы рәвештә венок салыначак. Соңрак Совет районы скверында традицион концерт булачак. Шул ук көнне Кремль алдында Казан хәрби гарнизоны һәм колонна катнашында парад була. **10.00 сәгатьтә** Җиңү паркында бәйрәм чаралары старт ала. Анда реставрацияләнгән сугыш чоры техникасы экспозициясен күреп булачак. **18.00 сәгатьтә** Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында сугыш корбаннарына багышланган концерт булачак, анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашачак. Бәйрәм программасы 22.00 сәгатькә кадәр дәвам итәчәк һәм ул бәйрәм салюты белән тәгәлләнәчәк.

Казанга «Алтын алма» тапшырдылар

Татарстан башкаласы FIJET Golden Apple («Алтын алма») бүләгенә ия булды. Кинематография өлкәсендәге «Оскар»га тиң булган әлеге бүләк Россиянең бары тик Сызрань һәм Мәскәү шәһәрләренә генә тапшырылган булган. Казан – илнең мондый бүләккә ия булган өченче шәһәре.

metshin.ru

FIJET премиясе ел саен туризмны үстерүгә зур өлеш керткән билгеле бер илгә, шәһәргә, оешмага яки шәхескә бирелә. FIJET Golden Apple туризм турында язучы журналистларның халыкара федерациясе 1970 елда оешкан. Премия лауреатлары арасында Италиянең Сицилия, Хорватиянең Дубровник, Бөекбританиянең Йорк, Польшаның Краков, Бельгиянең Антверпен, Мисырның Южный Синай шәһәрләре бар.

Бүләкне тапшыру тантанасында катнашкан FIJET президенты Тиджани Хаддад сүзләренчә, Казан әлеге премиягә лаек. Казан вакыйга туризмын, мәдәни-тарихи мирасны үстерү, шәһәр брендын таныту буенча күп эшләр башкара.

– Мин Казанга узган ел пресс-тур белән килгән идем. Шәһәр үзенең кунакчыл, киң күңелле булуы белән ошады. Биредә конфессияләр үзара дус, тыныч яшиләр. Мәдәни мираска да игътибар зур. Республиканың табигате дә искиткеч, – диде ул.

Казан мэры Илсур Метшин сүзләренчә, шәһәребезнең шушы зур бүләккә ия булуы – горурлык. Моңа ирешү өчен күп эшләр эшләнә. Соңгы ун елда туристлар агымы ун тапкырга арткан.

– Туризмны үстерү буенча яңадан-яңа проектлар уйлап табабыз. Бүген тагын бер яңа проект турында әйтәсем килә. Аның идеясен язучы Илдар Абузяров тәкъдим итте һәм ул безгә ошады. Ул Казанга чит илләрдән, Россия шәһәрләреннән язучы, блогер, журналистларны чакырырга һәм аларга бер-ике айга яшәргә фатир бирергә, әсәрләр, мәкаләләр язарга грантлар бүлеп бирергә тәкъдим итте. Әсәрләрнең төп геройлары исә Казан халкы булырга тиеш. Мондый практика дөньяның күп кенә илләрендә бар инде, нишләптер әлегә Россиядә ул кулланылмый. Бу башлангыч уңышлы булыр дип уйлыйбыз, – диде ул.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Евгения Маслова:

«Сугышчыларның ярдәм сорап ялваруларын әле дә ишетәм күк»

→ **Ахыры. Башы 1нче биттә.**

Көньяк, Көнбатыш, Воронеж, Көньяк-көнбатыш фронтларында хезмәт итәргә туры килә аңа. Көненә йөзләгән яралы, туктаусыз операцияләр, ачлык- ялангачлык һәм җиңүгә өмет. «Аякта басып тора алмаслык хәлдә булсак та, ял, ашау, йоклау турында уйлау да юк иде. Сугышчыларның ярдәм сорап ялварулары әле дә колагымда яңгырый сыман. Мине сугышта Ходай саклады», – ди үзе. Колагына мина кыйпылчыгы эләккәч тә, инвалидлык буенча группа алудан баш тарта. 1944 елны демобилизацияләнеп, туган якларына кайта.

Сугыштан соң Евгения ханым Казан медицина институтын тәмамлый. Үз вазифасын бик яратып башкара. 75 яшенә кадәр күз табибы булып эшли. Яшьли ярәшкән,сугышны кичкән Сергей Игнатьевич белән гаилә корып, дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Төпчек кызы Иринаны Евгения ханым 49 яшендә таба. Бүген ул – биш оныгы, алты оныкчыгы өчен яраткан әби.

– 9 Май безнең өчен зур бәйрәм. Әни янына элек бергә сугышкан дуслары да килә иде. Хәзер инде исәннәре калмады да. Әни – безнең горурлыгыбыз, үрнәк алыр кешебез. Без аның көчле булуына, түземлегенә, батырлыгына сокланабыз, аңа озын гомер телибез, – диләр кызлары Ирина белән Светлана.

Моннан ике ел элек Бөек Җиңүнең 70 еллыгында Евгения Маслова парадка да чыккан булган. Биеп, барысын да шаккатырган. Бүген авыррак хәрәкәтләнсә дә, җырлавыннан туктамый. Без дә аның белән бергәләп сугыш җырларын искә төшердек. Тумышы белән Чувашия Республикасыннан булган Евгения ханым татарча, марича, чувашча да яхшы аңлый.

II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, сугышта күрсәткән батырлыклары өчен медальләр аның бәйрәмгә генә кадерләп кия торган костюм түшендә урын алган. Евгения Маслова – сәламәтлек саклау өлкәсенең почетлы ветераны да.

– Иң кадерлесе – сәламәтлек, һәрчак елмаеп, матур булып яшәгез. Сезгә карап, сәламәт дип әйтерлек булсын. Тормышның кадерен белергә өйрәнегез. Бәхет, мәхәббәт һәрчак янәшәгездә булсын, – дип, укучыларыбызга теләкләрен җиткерде ул.

«Үзегезне саклагыз, киләсе елга да кунакка килерсез. Миңа авырырга ярамый, 100 яшьлегемне уздырам, Алла боерса», – дип озатып калды безне. Амин, кабат очрашулар насыйп булсын!

КИСКЕН МӘСЬӘЛӘ

«Эшләр идем – калхуз юк»

Россиядә 12 миллионнан 25 миллионга кадәр кеше үзмәшгуль, ягъни үзләре өчен генә эшләүчеләр дип исәпләнә.

Федерация Советы дәүләт белән үзмәшгульләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләргә тиешле хокукый кагыйдәләрне 2017 ел ахырына әзерләп тәмамларга ниятли. Федерация Советының социаль сәясәт комитеты рәисе Валерий Рязанцев сүзләренә караганда, үзмәшгульләр дәүләткә салым түләми, Пенсия фондына акча күчереп бармый.

– Үзләре өчен генә эшләүче кешеләр пенсияне тулы күләмендә алмаячаклар, чөнки пенсия билгеләү стаждан һәм баллардан тора. Әгәр кешедә стаж юк, ә минимум баллар гына булса, аңа картлык буенча билгеләнә торган пенсияне көтәргә туры киләчәк, – ди Валерий Рязанцев.

Иминият пенсиясенә ирешмәгән кешеләргә картлык буенча социаль пенсия ир-атларга – 65, ә хатын-кызларга 60 яшьтән генә билгеләнә. Быел социаль пенсия уртача – 8774 сум.

Федерация Советы үзмәшгульләрнең чит илгә чыгу мөмкинлеген дә чикләргә җыена. Ашыгыч медицина ярдәме алу хокукы калдырыла.

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы да үзмәшгульләргә, эшкуар сыйфатында теркәлмичә генә, эшчәнлек алып бару шартларын билгеләүче закон проектын карый. Әлеге закон проекты авторлары – депутатлар Павел Крашенинников белән Андрей Макаров аңлатуынча, кайбер төр эшчәнлек алып баручы гражданнар шәхси эшкуарлар өчен мәҗбүри булган таләпләрдән азат ителәчәк.

Дәүләткә салым түләмичә, Пенсия фондына акча күчермичә үзең өчен генә эшләп яшәү яки рәсми эш урынында хезмәт хакының яртысын «конвертта» алу – яшь һәм сау-сәламәт чакта рәхәт нәрсә кебек, әлбәттә. Ләкин бу рәхәтлекнең кешене гомер көзендә хәсрәт рәвешендә каршылавы ихтимал шул.

Россиядә пенсияләр билгеләүдә 2015 елның 1 гыйнварыннан яңа кагыйдәләр кертелде. Элек ир-атларга – 60, ә хатын-кызларга 55 яшь тулгач иминият пенсиясе билгеләү өчен, биш ел стаж булу да җитә иде. Хәзер иминият пенсиясе өчен, кимендә, 15 ел стаж кирәк. Бу таләп этаплап кертелә: 2017 елда пенсиягә чыгучыларга – 8 ел, 2018 елда – 9 ел, 2019 елда 10 ел. Унбиш ел стаж булу 2025 елдан мәҗбүри шарт.

Шактый гына авылларда бүген тәгаен эш урыны юк. Типсә тимер өзәрдәй ир-атлар, иген кырын җырлап урып чыгардай хатын-кызлар: «Эшләр идек – калхуз бетерелде», – дип зарланалар. Андыйларны нинди картлык көтә? Федерация Советы һәм Дәүләт Думасы ел ахырына үзмәшгульләрне кайгырткан халыкчан закон кабул итәр дип өметләник.

Дамир БӘДРИЕВ.

Өчпочмаклы хатлар

Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитеты Җиңү бәйрәме алдыннан сугыш еллары хатлары күргәзмәсен оештыра. Архив хезмәткәрләре фронтта булган вакыйгаларны сәгате-минуты белән гәүдәләндергән хатларны туплаган. Сугыш еллары хатлары – дары исе сеңгән, вакыт һәм солдатларның күз яшьләре белән сугарылган өчпочмаклы хәтер ул. Алар гап-гади егетләрнең Ватаннарына тугрылыклары турында сөйли. Хатлар туганнарга һәм дусларга, хезмәт коллективларына, хөкүмәт органнарына, газета редакцияләренә юлланган.

Казанның Ново-Песочная урамының 44нче йортында урнашкан күргәзмә залында аерым бер блок Советлар Союзы язучыларының фронт хатларына багышланган. Алар арасында Муса Җәлилнең ТАССР язучылар союзы рәисе Туфан Имаметдиновка, Атилла Расихның әти-әнисенә, Әхмәт Исхакның хатыны һәм уларына атап язган хатлары бар. Шулай ук гадәти булмаган әлеге күргәзмәдә Гадел Кутуй, Михаил Бубенов, Ибраһим Гази, Нури Арслан, Сибгат Хәким, Зәки Нури һәм башка язучыларның хатларын да күрергә мөмкин.

Хәзерге вакытта Татарстан архивында фронттан килгән 3,5 мең тирәсе хат саклана.

Ишетмәсәләр дә, ишеттерә беләләр

Ишетмәүчеләр арасында DeafSkills халыкара һөнәри осталык ярышлары катнашучыларын бер дә мөмкинлекләре чикле димәссең. Алар, «мин үзгә» дип, дүрт дивар арасында бикләнеп ятмый. Киресенчә, ишетмәсәләр дә, җәмгыятькә үз фикерен ишеттерә белә андыйлар.

Алисә САБИРОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Казан кызы Лилия Әскәрова да тумыштан ишетми. Тормышта үз һөнәрен табарга аңа кайчандыр әнисе ярдәм иткән. Ун ел элек кыз, аның киңәше белән, сәнгать мәктәбендә чәчтараш һөнәрен үзләштерә. Бу һөнәре аңа, даими керемнән тыш, тормышта югалып калмаска да ярдәм итә.

– Эшкә мин танышларым аша урнаштым. Минем кебек кешеләр барысы да шулай эшли, башкача булмый. Баштарак эшкә кереп китү кыен иде. Миңа бит клиент белән аралашырга, аның фикерен тыңларга кирәк. Кешенең ни әйтергә теләгәнен йә язып белә идем, йә иреннәре хәрәкәтеннән сүзләр тәэзи идем. Тора-бара даими клиентларым да барлыкка килде. Аларны мин инде сүзсез аңлыйм. Хәзерге вакытта мин декрет ялында, – диде Лилия.

Казан төзелеш көллияте бинасында Мәскәү, Свердловск өлкәсе, Удмуртия, Татарстан белән Башкортстаннан килгән 50гә якын яшь белгеч үзен ун һөнәр буенча сынап карады. Чәчтараш һөнәреннән тыш биредә тагын лаборатор-химик анализ ясаучы, агач остасы, ашсу остасы, фотограф, флорист, тимерче, буяучы, ташчы, челтәрле һәм системалы идарә белгече кебек һөнәрләр дә бар иде. Оештыручылар сүзләренчә, бу белгечлекләрнең исемлеге елдан-ел зураячак әле.

DeafSkills – дөньяда тиңе булмаган беренче чемпионат ул. Татарстан Республикасының Президент ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева сүзләренчә, аның Казанда узуы аеруча әһәмиятле.

– Татарстан өчен бу бик мөһим чара. «Бер-береңне ишетергә өйрәнү» дигән сүз бар, нәкъ менә бүген без башкаларны ишетергә, тыңларга, аңларга өйрәнәбез. Бер-береңне ишетү өчен биредә никадәр зур һәм авыр эш башкарыла. Бу, бер яктан, яшь белгечләргә юл салу, икенче яктан, безне шундый шартларда эшләргә өйрәтү чарасы да, – диде Ләйлә Фазлыева.

Татарстанда 6 меңгә якын кеше начар ишетә яисә бөтенләй ишетми. Шуларның 32 проценты гына эшкә урнашкан. Ә дөнья күләмендә ишетмәүчеләрнең 25 проценты белем алудан бөтенләй мәхрүм. Бу тигезсезлекне бетерү максатыннан, DeafSkills мәйданчыгында ишетмәүчеләр өчен вакансияләр ярминкәсе оештырылды. Дистәләгән оешма бу яшьләрне үз кулы астына алырга риза иде. Никита Хоркин да, чемпионатта ашсу осталыгы буенча төп эксперт булуга карамастан, бер үк вакытта үз кулы астында эшләргә сәләтле белгечләрне дә барлый иде.

– Ишетмәүче кеше үз өлкәсендә сәләтле белгеч була ала. Андыйларның дөньяга карашы үзгә, фикерләре дә креатив, – ди Никита.

Әйтергә кирәк, яшь белгечләргә бирелгән биремнәр WorldSkills стандартларына охшаш булса да, аннан бераз гына йомшаграк бәяләнә.

– Ишетмәүчеләр эшли алмый дип уйлыйсызмы? Ялгышасыз! Алар дөньяны үзгәртә ала. Бу ярышлар – дөньякүләм мөһим чара. Без һәр җирдә, беренче чемпионат Казанда үтте, дип сөйләячәкбез, сез тарихка кереп калдыгыз. Татарстан Президентына, республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгына, аны уткәрергә ярдәм иткәне өчен, зур рәхмәтемне җиткерәм, – диде Бөтендөнья ишетмәүчеләр федерациясе президенты Колин Аллен.

Пенсиягә кагылышлы соравың булса

Бөек Җиңүнең 72 еллыгы уңаеннан, Россия Пенсия Фондының Татарстан бүлеге ветераннар өчен «кайнар элемтә» номеры ача.

5 май көнне сәгать 9.00дән 15.00гә кадәр **8-800-100-26-27** номеры аша пенсия түләүләре, социаль хезмәтләр җыелмасы һәм пенсиягә кагылышлы башка сорауларга җавап табарга мөмкин булачак.

«Студентлар язы» җиңүчесе Путин стипендиясен алачак

Бүген республика студентлары өчен зур бәйрәм – УНИКС концертлар залында «Татарстан Республикасы студентлар язы» гала-концерты уза. Җиңүчеләр 15-20 май көнне Тула белән Мәскәү шәһәрендә узачак «Россия студентлар язы»нда катнашу хокукына ия булачак. Ә инде ил этабын да узган иҗат төркемнәре Россия Президенты Владимир Путин исеменнән бирелгән стипендиягә ия була.

Фестивальдә Татарстан командасы абсолют чемпион буларак катнаша, чөнки безнең төбәк – икенче ел рәттән «Студентлар язы»ның Гран-при иясе. Быел республика фестивалендә 3 меңгә якын студент катнашкан. Бу – Казан, Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Яшел Үзән шәһәрләре зона-этабында сайлап алынган иң көчле номерлар.

– «Студентлар язы» сәхнәдә яңгыраган җырлар «солянкасы» гына түгел. Һәр вуз чыгышының үз программасы, тематикасы, мәгънәсе бар. Быел Казан Кооператив институты шаккатыргы – алар номерларын сәхнәдә түгел, ә Игенчеләр Сарае алдында күрсәтте. Бу алымны жюри әгъзалары да югары бәяләде. Казан (Идел буе) федераль университеты студентлары «Город Эмбер» (Джин Дюпро) китабында барган вакыйгаларны студент тормышы күзлегеннән күрсәтте. Гомумән, яшьләр мәңгелек проблемаларны замана китаплары, кино сәнгате аша күрсәтергә ярата. Казан дәүләт энергетика университеты – театр сәнгатендә лидер. Аларның «Сдвиг» яшьләр театры да бар, – ди Казан шәһәре Башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре бүлеге рәисе Айрат Фәизов.

Фестивальдә мөмкинлекләре чикле студентлар да үз иҗатын күрсәтә ала. Бу юнәлештә Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе, Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты (КАИ), Федераль университет студентлары эшли. Ә киләсе елдан мөмкинлекләре чикле студентларны аерым бер номинациядә бәяләячәкләр.

– Фестивальнең районнарга күчүе аеруча сөенедерә. Казаннан тыш та безнең сәләтле, креатив яшьләр бар бит әле. «Студентлар язы»ның зона этабының кече шәһәрләргә күчүе «2030 стратегиясе»нә дә нигезләнгән, – диде «Студентлар лигасы» президенты Элькин Искендеров.

Иҗади студентларны югары уку йортлары үзенчә бәяли. «Студентлар язы»нда үзен күрсәтүче яшьләр стипендияне 10 меңнән дә ким алмый.

Резеда САДРИЕВА.

Тату сыйныф серләре

Бала тәрбияләү шикелле мөһим эштә әти-әниләр һәм мәктәп бердәм булып, кулга-кул тотынышып эшләгәндә генә зур уңышларга ирешеп була. Соңгы вакытта бу бәйләнеш ничектер йомшабрак китте шикелле. Әти-әниләр балаларын тәрбияләүне мәктәп өстенә аударырга, ә мәктәп «безнең максат – белем бирү генә» диярга ярата башлады.

Шушы гаилә һәм мәктәп арасындагы бәйләнешне ныгыту өчен, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы «Тату сыйныф серләре» дигән бәйге башлап җибәргән иде. Мәктәп-гимназия сыйныфларындагы әти-әниләр комитеты өчен махсус оештырылган ул. Республика буенча бу ярышта 1380 сыйныф катнашкан, аларның 460ы – район күләменә, ә 50 команда республиканың финал ярышларына чыккан. Әлеге ярышта Казан шәһәреннән татар телендә белем бирүче 155нче гимназиясенең 5Б сыйныфының әти-әниләр комитеты да бар. Алар «Хезмәт тәрбиясе» дигән номинациядә мактаулы 2нче урынга лаек булганнар. Әлеге гимназиянең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Әлфирә Борһанова, 5Бның сыйныф җитәкчесе Фәнүзә Усманова, сыйныфның әти-әниләр комитеты рәисе Алсу Адагамова һәм иң актив әниләрнең берсе Розалия Бариева белән очрашып, әлеге җиңүнең нигезен тәшкил иткән алшартлар хакында сораштык.

– Сыйныфыбызда малайлар күбрәк, аларның саны – 17, кызларыбыз 11 генә. Гадәттә, мондый сыйныф белән эшләве бик ансат булмый. Ә бездә киресенчә. Чөнки балалар, бәхеткә, барысы да тулы, тату гаиләләрдә үсәләр. «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр», диләр бит. Ә безнекеләрнең оялары нык, таза. Әти-әниләре балаларын тәрбияләү һәм белемле итү өчен бөтен тырышлыкларын куялар. Балалар бик җаваплы, бер-берсенә ярдәмчел. Сыйныфыбызда мөмкинлекләре чикләнгән бер малай бар. Мәктәптә эвакуация өйрәнүләре вакытында иптәшләре аны иң беренче чыгарганнарын белгәч, күзләремә яшь тыгылды, – ди сыйныф җитәкчесе.

– Бәйге турында күрсәтмә килгәч, гимназиянең шактый сыйныфлары катнашып карарга булды. Ләкин 5Бларга җиткәне булмады. Яшерен-батырын түгел, хәзер кайбер мәктәпләрдә балаларга хезмәт тәрбиясе бөтенләй бирелми диярлек. Бездә алай түгел. Киресенчә, кечкенәдән үк бала үз хезмәтенең җимешен татысын, шуңа сөенергә өйрәнсен дип тырышабыз. Гимназиябездә елына дүрт-биш тапкыр хәйрия ярминкәләре уздырыла. Ә аңарчы балалар төрле түгәрәкләрдә үз куллары белән матурлык булдыра: чәчәкләр ясый, картиналар яза. Аларны сатудан кергән акчаны ярдәмгә мохтаҗ яшьтәшләренә илтеп бирәләр. Бер атуда ике куянны тотабыз. Эшкә дә, игелеклe булырга да өйрәтәбез,– ди директор урынбасары. – Конкурска шушы эшләребез хакында яздык.

Ә бит әти-әниләргә мәртәбәле жюри каршында чыгыш ясарга да туры килгән. Ярый әле Алсу Әбелханова, Губскийлар гаиләсе шикелле артистлары да бар. Бөтенесе бер булып тырышканнар. Иң мөһиме, бу эш болай да дус-тату булулары белән гимназиядә аерылып торган сыйныф укучыларын һәм аларның әти-әниләрен тагын да дуслаштырган.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Татарстан халыкларының III съезды резолюциясе

«Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру турында»

Казан **2017 елның 22 апреле**

Без, Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләре, ТР халыклары съездына җыелып, Россия Федерациясендә милләтара һәм динара тынычлык-татулыкны ныгыту, милли телләр һәм мәдәниятләрне саклау-үстерү, рухи уртаклыкны көчәйтү, гражданнарның конституцион хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү ягында торуыбызны белдерәбез.

Съезд, Россия җитәкчелегенең, чын мәгънәсендә федератив демократик дәүләт буларак, илне үстерүгә, аның халыкара мәйдандагы мәнфәгатьләрен эзлекле төстә яклау һәм халыкара терроризмга каршы көрәшкә юнәлдерелгән стратегик линиясен тулысынча хуплый.

Бүгенге катлаулы шартларда Россия Федерациясенең күп милләтле һәм төрле конфессияле булуы аеруча актуальләшә. Ил эчендәге һәм илебездән читтәге дошманнарыбыз дәүләтне какшату, Россия җәмгыятен таркату өчен этнодини өлкәне сәясиләштерү омтылышларын туктатмый.

Киң җәмәгатьчелек ил җитәкчелегенең дәүләт милли сәясәт стратегиясен кабул итү, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык булдыру, максатчан дәүләт программаларын тормышка ашыру турында карарлары һәм гамәлләрен тулысынча хуплый. Әлеге тәкъдимнәр Татарстан халыклары икенче съездының Россия Федерациясе Президентына, Федераль Җыены һәм Хөкүмәтенә мөрәҗәгатьтә урын алган иде. Кабул ителгән карарлар милли һәм дини җирлектә киеренкелек күренешләрен кисәтү, барлык халыклар вәкилләренең яңаны булдыру юлындагы үсешенә ярдәм итәрдәй ихтирамлы мөнәсәбәтләр тудыруга уңай алшартлар китереп чыгара.

Җәмгыятьтә Россия ватанпәрвәрлеге кыйммәтләрен ныгыту, илебезнең күпмилләтле халкының бердәмлеге, тупланганлыгын аңлау мондый сәясәтнең мөһим нәтиҗәләреннән берсе булып тора.

Лидер төбәкләрнең берсе, икътисад, социаль өлкәдә югары күрсәткечләргә ирешүче, милләтара һәм динара тынычлык-татулыкны, иҗтимагый һәм сәяси тотрыклылыкны саклап килүче Татарстан Республикасы Россия Федерациясен үстерүгә саллы өлеш кертә.

Бүгенге Татарстан якын һәм ерак чит илләрдәге күп кенә дәүләтләр белән хезмәттәшлеккә карата ачыклыгы, рухи байлык һәм мәдәниятнең традицион кыйммәтләре ягында булуы белән аерылып тора.

Сәяси курсның дәвамчанлыгы, Татарстан халыкларының тарихи-мәдәни һәм рухи мирасына ихтирам хисе җәмгыятебез тормышының барлык якларына уңай йогынты ясый. Борынгы Болгар, Свияжск утрау-шәһәрчеге һәм Казанның тарихи ядкәрләрен торгызу эше Татарстанда яшәүчеләрне әхлаклылык һәм гуманизм рухында тәрбияли, республиканың уңай имиджын булдыруга ярдәм итә. Бу күпкырлы эштә Татарстан Республикасының Беренче Президенты М.Шәймиев җитәкчелегендәге «Яңарыш» фонды гаять зур роль уйный.

Шуны билгеләп үтү мөһим: бүген Татарстанда ни генә эшләнмәсен, барысы да, нинди милләттән булуларына һәм нинди дин тотуларына карамастан, кешеләребез мәнфәгатьләренә җавап бирә. 2030 елга кадәрге чорга эшләнгән һәм тормышка ашырылып килә торган Татарстанның Социаль-икътисади үсеш стратегиясе төп өстенлекле юнәлеш сыйфатында кеше капиталын камилләштерүне күздә тота.

Республика торган саен үзенә күбрәк җәлеп итеп килгән төбәккә әйләнә, Татарстанда этник төркемнәр саны арта, мигрантларны социаль һәм мәдәни тормышка җайлаштыру, интеграцияләү бурычлары уңышлы төстә тормышка ашырыла.

Шул ук вакытта Татарстанда яшәүчеләрнең барлык этноконфессиональ төркемнәренең күп гасырлар дәвамында үзара тыныч-тату яшәүгә корылган бердәмлеге һәм татулыгы бөтен җәмгыятебезнең кыйммәт ориентиры һәм көндәшлеккә сәләтендәге өстенлеге булып тора.

Әлеге нигезләмәләр 2013 елда кабул ителгән, Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең яңа редакциядәге концепциясендә чагылыш тапты. Татарстан Республикасы Президенты каршында оештырылган Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр советы эшчәнлеге бу өлкәдә өстенлекле юнәлешләр эшләүгә һәм этнодини мөнәсәбәтләрнең торышына уңай йогынты ясый.

Милләтара һәм конфессияара тынычлык-татулыкны ныгытуга, телләр һәм мәдәниятләрне саклау, үстерү, татар халкын милләт буларак саклау, кәсепчелекне һәм традицияләрне үстерүгә ярдәм итүгә, шулай ук экстремистлык һәм террорчылыкны кисәтүгә юнәлдерелгән өч дәүләт программасы һәм алты кече программа тормышка ашырылып килә. Муниципаль дәрәҗәдә комплексы программалар эшләнгән.

Татарстан халыкларының моңа кадәрге съездыннан соң үткән дистә ел эчендә республикабызның күп милләтле хәрәкәте җитди уңышларга иреште. Бу уңышларда Татарстан Халыклар ассамблеясы төп роль уйный. Ассамблея 36 этносның 210нан артыграк милли-мәдәни берләшмәсеннән гыйбарәт. Казанда, Чаллы, Лениногорск, Менделеев, Түбән Кама, Нурлат һәм Тәтеш шәһәрләрендә ассамблеяның ресурс үзәкләре булып торган җиде Халыклар дуслыгы йорты эшләп килә.

Традицион диннәр рухи үсешкә зур өлеш кертә. Дәүләти-конфессиональ мөнәсәбәтләрнең үсеше моңа ярдәм итә. Халыклар бердәмлеге көнендә – 2015 елның 4 ноябрендә – Татарстан Республикасы Президенты Р.Миңнехановның «Болгар ислам академиясен булдыру һәм Казан Изге Мәрьям Ана иконасы соборын торгызу турында» Указын кабул итү тарихи гаделлек һәм дини берләшмәләргә ярдәм итү үрнәгенә әйләнде. Православие соборын торгызу һәм мөселманнарның рухи-агарту үзәген булдыруның республикада яшәүчеләрнең барчасының ярдәмендә тормышка ашырылуы мөһим.

Татарстан Республикасы халыкларының беренче (1992 елда), икенче (2007 елда) съездлары карарларында дәвамчанлык һәм эзлеклелек күзәтелә. Аларны үтәү дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруда нәтиҗәле бербөтен система булдыру мөмкинлеге бирде. Ул законнар, норматив актлар һәм максатчан программаларының тулылыгы, этномәдәни инфраструктурасының нык үсешле булуы, иҗтимагый этномәдәни берләшмәләрнең югары дәрәҗәдә җәлеп ителүе һәм аларның дәүләт, муниципаль хакимият органнары белән тиешле дәрәҗәдә хезмәттәшлеге белән аерылып тора. Даими рәвештә үткәрелеп килә торган сорашып белешү нәтиҗәләренә караганда, халыкның 80 проценттан артыграгы милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышын уңай бәяли.

Шуның белән бергә, дөнья күләмендә низаглар һәм радикализмның таралу куркынычы, иҗтимагый үсеш чынбарлыгы милли сәясәтне тормышка ашыру өлкәсендә нәтиҗәле, үтемле эш ысулларын, дәүләт, муниципаль һәм иҗтимагый структураларның бер йодрыкка тупланып эшләвен көчәйтүне таләп итәрдәй яңа бурычлар куя.

Без, Татарстан Республикасы Президенты Р.Миңнехановның «Россиянең көче – халыклар бердәмлегендә!» дигән темага чыгышын һәм съезд делегатлары чыгышларын тыңлап, фикер алышканнан соң:

– Россия Федерациясе Президенты В.Путин тарафыннан илнең куәтен ныгыту, этносара һәм динара тынычлык-татулыкны саклау, экстремистлык һәм террорчылык күренешләренә каршы көрәш буенча үткәрелеп килә торган сәясәткә теләктәшлек белдерәбез;

– барлык сәяси көчләр һәм хәрәкәтләр вәкилләрен илдә тынычлыкны, төрле милләтләр, төрле дин тотучылар арасында татулыкны үстерүгә, этноконфессиональ өлкәдә киеренкелеккә китерердәй гамәлләргә юл куймаска ярдәм итүгә өндибез;

– Татарстан Республикасында булдырылган дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның бербөтен системасын, аның ведомствоара һәм комплексы характерда булуын хуплыйбыз;

– этномәдәни күптөрлелекне, рухи яңарыш, Татарстанда милләтара һәм динара тынычлык-татулыкны саклап калуга ярдәм итүне эшебездә төп юнәлеш буларак исәплибез;

– террорчылык, экстремистлык һәм радикализмның (нинди генә милли һәм дини «кием»гә төренүләренә карамастан) – җитди социаль хәвеф, җәмгыятьнең бердәмлегенә янау, ә бу җимергеч тенденцияләргә каршы көрәшнең – барлык дәүләт һәм муниципаль идарә буыннарының, гражданлык җәмгыяте институтларының гомуми бурычы булып торуына иманыбыз камил;

– милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрнең торышын даими өйрәнү, низаглы хәлләрне кисәтү максатыннан, интеграцияле этнологик мониторинг системасын үстерүне кирәк дип саныйбыз;

– этномәдәни үсеш өлкәсенә җаваплы кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү эшен камилләштерүгә ихтыяҗны искәртәбез;

– дәүләт милли сәясәтен мәгълүмати-агарту юнәлеше белән бергә алып бару эшенең сыйфатын яхшырту чараларын күрергә кирәк, дигән фикердә торабыз;

– муниципаль дәрәҗәдә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру эшчәнлегенең әһәмияте үсүен, муниципаль программаларны һәм заманча эш методикалары, формаларын актуальләштерү зарурылыгын билгеләп үтәбез;

– республикада Татарстан Халыклар ассамблеясы тарафыннан үткәрелеп килә торган республикада күпмилләтле хәрәкәтне үстерү буенча күпкырлы эшне хуплыйбыз һәм аның инфраструктурасын камилләштерү зарурылыгын искәртәбез;

– халыклар арасында дуслык-татулыкны ныгытуга, шулай ук Татарстанның, тулаем алганда Россия Федерациясенең социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси үсешенә хәлиткеч йогынты ясаган Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара эшләр бүлешү турында шартнамәнең уңай роль уйнавына ышанабыз.

Без, съезд делегатлары, Россия Федерациясе Президенты һәм Федераль Җыенына түбәндәге тәкъдим белән мөрәҗәгать итәбез:

– Татарстанның күпмилләтле халкы фикерен, шулай ук республикада үзен уңай яктан таныткан югары дәүләт хакимияте оештыру формасын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты вазифасы атамасын саклап калу;

– Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара эшләр бүлешү турында шартнамәнең гамәлдә булу вакыты чыгу сәбәпле, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына федераль үзәк белән Татарстан арасындагы вәкаләтләр чикләрен билгеләүгә кагылышлы мәсьәләләрне җайга салу формаларын эшләргә йөкләүне.

Без Россия Федерациясенең киләчәген, халыкара мәйданда ил мәнфәгатьләрен яклауның барлык халыкларның этномәдәни үсешен тәэмин итәрдәй демократик федератив дәүләт сыйфатында ил куәтен ныгыту һәм үстерүнең гаранты буларак, Владимир Владимирович Путин белән аерылгысыз бәйлибез.

Кабул ителгән карарларның Татарстанда дәүләт милли сәясәтенең төп максатларына ирешүгә, республикада яшәүче халыклар вәкилләренең тагын да ныграк тупланыуна, тулаем Россиядә милләтара һәм динара тынычлык-татулыкны ныгытуга ярдәм итәсенә ышанабыз.

Николай Владимиров, Татарстан халыклары ассамблеясы советы Башкарма комитеты җитәкчесе:

– Республикада милли сәясәт өлкәсендә бай тәҗрибә тупланды. Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгыту буенча дәүләт программалары эшли. Һәр милләткә үзенең телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү мөмкинлеге бирелә. Җиде район җирлегендә Халыклар дуслыгы йортлары ачылды, алар алга таба да ачылачак. Шулай ук районнарда Татарстан Халыклары ассамблеясы вәкилләкләре дә эшләп килә. Резолюция алга таба да республикада яшәүче төрле милләт кешеләренең бердәм булып туплануына ярдәм итәсенә ышанабыз. Тынычлык булганда, республика икътисади яктан да үсә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бу сүзләрен еш кабатлый. Президент дигәннән, резолюциядә Татарстан Президенты вазифасы атамасын саклап калу тәкъдиме дә бар. Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә, Рөстәм Миңнеханов та милли-мәдәни оешмаларның эшчәнлегенә һәрчак хәерһахлы булды. Безнең теләк-үтенечләрне ишетеп торалар.



ДАРЫ ИСЕ СЕҢГӘН КӨНДӘЛЕК

Айсылу ханым Гарифуллинага ядкәрләр белән танышырга музейга барып йөрисе юк. Бөек Ватан сугышы ветераны кызы өендә андыйлар шактый. Әтисенең дары исе сеңгән, шигырь белән язган көндәлеге – аларның иң кадерлесе. Аны сакланып кына кулына алып, саргайган битләрен ачканда, Айсылу ханым әтисенең данлы сугышчан юлы буйлап узгандай була.

18 яшьтә һәр көнделә шагыйрь яши, диләр. Әлеге көндәлек тә моның нәкъ шулай икәнен исбатлый. 1924 елның 1 августында Теләче районының Казаклар авылында туган Ибраһим Гарифуллинның яшьлеге җиткәнне генә көтеп торган диярсең, фашист мәлгунь сугыш башлый. Җиденче сыйныфны тәмамлап, колхозга булышып йөргән егет ил алдына куркыныч килгәндә өйдә кала ала димени?! 1943 елның язында армия сафына алынып, фронтка китә. Үзе белән дәфтәр битләреннән тегеп ясап, блокнот, каләм дә ала. Кайда булганын, ниләр күргәнен, сугышның бөтен авырлыкларын шигырь юлларына салып бара. Яшьлегенең иң матур, өметләренең бөреләнгән чагында туган авылыннан, кадерле кешеләреннән аерылып, үлем-кан, коточкыч югалтулар белән очрашу хисле егет кулына каләм алдыра. Шагыйрь булмаса да, хисләренең ихласлыгы сүзләрен ук итә. Менә көндәлекне ачучы «Повестка алгач – фронтка» дигән шигырь.

Тревога! Тревога! – безгә хәбәр
Китәргә фронтка.
Поезд да моңсу кычкырта,
Безне фронтка озата.

Ә бу юллар «Сугыш кыры» дигән шигырьдән:

Поезддан төштек Курскида,
Таралдык урманга барыбыз да.
Көтәбез приказ булганны,
Винтовка кулыбызда.

Ибраһим солдат каты сугышларда катнашып, Днепр елгасын кичеп, Киев, Житомир шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Көндәлектә бу хакта да шигырьләр бар:

Менә ул зур һәм киң Днепр,
Анда юк бернинди күпер.
Немецлар Киевны бирмәс өчен,
Зур техника белән каршы тордылар.
Урам өчен түгел, һәр йорт өчен
Штык сугышына тотындылар.

Житомирны азат итү дә шактый зур югалтулар хисабына була:

Баһадирдай йоклый иптәшләрем
Арып килеп сугыш эченнән.
Җил ыжгыра тышта куәтләнеп,
Көлгән кебек солдат кешедән.
Күп йөредем сугыш кыры буйлап,
Юллы юлсыз урман яланда.
Уйланмаган күп уйларны уйлап,
Окопларда кундым саламда.

Немец самолетларын менә ничек образлы итеп сурәтли яшь солдат:

Килә ул күкне караңгылап,
Кара болыттай шом булып.
Тугыз башлы аждаһадай улап,
«Йотабыз!» – дип канга тончыгып.
Моторлары каты улаттырып,
Чөелделәр тилгән шикелле.
Үлем көен уйнап баш очында
Асларыннан бомба сибелде.

«Самолетлар сугышы» дигән әлеге шигырьдә безнең самолетларның немец мессершмиттларын куып җибәрүләре турында язылган. Бу җиңүгә шатлык хисләре дә бар шигырьләрдә. Ә бит бу вакытта Ибраһим снаряд кыйпылчыгы тиеп, каты яраланып, госпитальдә ята. Шигырен дә шул чакта яза. Тизрәк терелеп, дошманны кыйныйсы килү теләген дә яшерми. Максаты изге егетнең яшь организмы сызлануларны җиңә, өч ай буе госпитальдә дәваланганнан соң ул, савыгып, атлы кавалериядә хезмәт итә башлый. Бендеровчыларга каршы барган сугышларда катнашып, Польша, Румыния һәм Венгрияне азат итү өчен барган яуларда ул кабат каты яралана.

Шинелемне өч җиреннән тиште
Пулеметның пулясы.
Пулемет уты астында калды
Иптәшләрнең күбесе.

Ул олы кайгы менә бу юлларга язылып, үчкә әверелә:

Хуш инде, якын дускай,
Синең өчен ачу алырбыз.
Синең ачудан туктамыйча,
Берлинга кадәр барырбыз.

Үлем белән көрәшеп, туган җирдән еракларда, чит илдә яраланып госпитальдә ятканда да егетнең кулыннан каләме төшми. Румыниядән кузгалып, санитар поездында унсигез тәүлек барганнан соң, Тбилисидан 150 километр ары Боржоми шәһәренә җитәләр. Егет анда да фронт хәбәрләрен газетадан укып ята:

Газетаның битен ачу белән,
Сводканы карадым.
Безнекеләр алган шәһәрләрне
Берәмтекләп санадым.

Ләкин кыю, курку белмәс сугышчының күңелендә үкенү хисләре дә бар:

Газетаны укыгачтын,
Фронт хәлләрен аңладым.
Тик шуңа үкенәм, немецны мин
Үз җирендә кыйный алмадым.

Сугыш бетү, Җиңү хәбәрен ул госпитальдә ишетә һәм бу шатлыкны көндәлеге белән дә уртаклаша:

Стенада радио сөйли.
Сугыш беткәнлеген аңлата.
Яралылар дикъкать белән тыңлый,
Бу шатлыкны бар да ярата.

Шигырьләрнең сихере булгандырмы, Ходай озын гомер язгангадырмы, авыр сугышларны кичеп, ярты Европаны урап, Ибраһим солдат, култык таякларында булса да, туган якларына кайта. Гимнастерка кесәсендә сугыш елларының шаһиты булган, инде шактый калынайган шигырь дәфтәрен дә алып кайта.

...Сиңа да бер кайтыр көнем
Булыр икән, туган илем.

Дары исе сеңгән әлеге көндәлектә тыныч көннәр шатлыгы, мәхәббәткә сусаган яшь җанның гомерлек ярын табуы да шигырь юлларына салынган. Ләкин туган якка кайткач, шигырьләр язарга вакыты калмый аның. Башка мәшәкатьләр арта. Сөйгән яры Мәймүнәгә өйләнеп, бер малай һәм биш кыз тәрбияләп үстерәләр. Алар хатыны белән икесе дә сатучылар булып эшлиләр. Коммунистик хезмәт ударнигы исеменә лаек булалар. Өч кызлары: Миңсылу, Гүзәл һәм Римма да әти-әнисе һөнәрен сайлый.

Без Айсылу ханым белән очраклы гына таныштык. Ахирәтенә ияреп, редакциябезгә килгән иде ул. Иҗат хакында сүз ара сүз чыгып, әтисенең шушы көндәлеге турында да сөйләде. Ул аны гаилә фоторәсемнәре белән бизәп, китап итеп тә бастырып чыгарган. Икенче юлы ул әлеге китапны һәм сугышлар шаһиты булган, битләре саргайган көндәлегенең төп нөсхәсен дә алып килде. Без аны фотосурәткә дә төшердек. 2016 елда «Школа» нәшриятында дөнья күргән бу китапка шул көндәлектәге шигырьләр күчереп басылган. Канлы һәм данлы сугыш елларының шаһиты булган, яу кырында иң якын сердәшенә әверелгән әлеге көндәлекне Ибраһим ага үзе исән чакта мәктәпкә бирә. Аннары әтисе вафатыннан соң кызы Айсылу, китап итеп бастырып, аның уй-хисләрен укучыга җиткерә.

Нюрнберг процессында фашистларны хөкем иткәндә, Ленинград блокадасында бөтен гаиләсе һәлак булган Таня Савичеваның көндәлеге дә гаепләүче дәлил буларак кулланылган. Ибраһим аганың дары исе сеңгән көндәлеге дә теләсә нинди мәхкәмәдә фашистларны кешелеккә каршы гамәлләрдә гаепләрлек.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

АЛАР БЕЗГӘ ҖИҢҮ КИТЕРДЕ

Ветераннарга – хөрмәт, сугышка – нәфрәт!

Мондый очрашу турында хәзер хыялланырга гына мөмкин дип уйлыйм. Борис Кириллович Кузнецов исемендәге кадетлар мәктәп-интернатында Җиңү бәйрәменә багышланган очрашуда Советлар Союзы Героеның үзен күрергә насыйп булды миңа. Аның Казанда туып-үсеп, гомер буе биредә яшәве дә күңелдә горурлык хисе уята.

Мәктәп-интернат Вахитов районында гомер итүче Бөек Ватан сугышы ветераннарын кунакка алды ул көнне. Арада Советлар Союзы Герое Борис Кузнецовның булуы – ике буын очрашуын тагын да мәртәбәлерәк итүе бәхәссез иде. Үзе бер тәрбия дәресе булды ул.

Кадетлар Советлар Союзы Герое отставкадагы полковник Борис Кузнецовны хәрбиләрчә тезелеп каршы алды. Мәктәп директоры подполковник Валерий Басов беренче сүз итеп аның хәлен, сәламәтлеген белеште. Урынлы кызыксыну. Сөбханаллаһ, 92 яшь тула икән ветеранга быел.

Укучылар исә тантана кунакларының һәрберсенә тигез хөрмәт күрсәтте. Биредәге Дан музеен да карадык. Үзенчәлекле спектакль дә әзерләгәннәр иде. Канкойгыч сугыш елларында балалар күргән михнәтләр бәян ителде анда: сугыш башлануы, чигенүләр, немец самолетларының тупка тотулары, концлагерьга эләгүләр, фашистларның явызлыклары, әти-әниләрнең һәлак булуы... Яшүсмерләргә генә хас җитдилек белән бирелеп уйнады яшь артистлар. Чын ихласлык күңелләрдә битарафлык калдырамы соң! Зал тын да алмый карадык. Спектакль тәмамлангач, Борис Кузнецов балаларга рәхмәт сүзләрен җиткерде. Очрашуны җитди тәрбия чарасы итә алган мөгаллимнәр, һичшиксез, мактауга лаек.

Ильяс САЛИХҖАН,
Казан.

«ҮЛЕМСЕЗ ПОЛК»: кайда һәм ничек?

Әлеге чарада катнашучылар нәрсәне белеп торырга тиеш

Мәгълүм булганча, 9 Майда бөтен Россиядә «Үлемсез полк» акциясе узачак. Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм тыл хезмәтчәннәренең фотолары куелган транспарантлар белән быел урамга 250 мең татарстанлы чыгар дип көтелә. Бу, узган ел белән чагыштырганда, 1,5 тапкырга күбрәк. Казанда гына да катнашучыларның саны 100 мең кешегә якын булачак.

Җыела башлау вакыты: 13.00
Җыелу урыны: Карл Маркс һәм Толстой урамнары кисешкән урында
Старт: 15.00
Маршрут тәмамлана: Меңьеллык мәйданы
Маршрут озынлыгы: 2 чакрым
Катнашучылар саны: 100 мең кеше
Оештыра һәм озата: 500 волонтер

Илдар Мөхәммәтҗанов фотоархивыннан

КАЙДА ҖЫЕЛАБЫЗ ҺӘМ НИЧЕК ХӘРӘКӘТ ИТӘБЕЗ?

Быел казанлылар өчен бераз үзгәртелгән маршрут тәкъдим ителә. Халык Карл Маркс һәм Толстой урамнары киселешендә сәгать 13.00дә җыела башлаячак. Узган елларны полк хәрәкәтенә кушылып китәр өчен өстәмә урыннар да билгеләнгән иде.

> **Транспарантны өйдә дә ясап була. Моның өчен:**
> – *фото табабыз;*
> – *аны компьютерда эшкәртәбез;*
> – *бастырып чыгарабыз;*
> – *әзер фотоны каты кәгазьгә яки пластикка беркетәбез. Шулай ук фотокысага да урнаштырырга була. Әмма пыяла урынына пластик сайлагыз;*
> – *фотога ныгытма ясыйбыз. Моның өчен сууткәргеч өчен торба (металлпластик булганы арзанрак) һәм ике ныгытма кирәк булачак. Ныгытманы икеякллы скотч ярдәмендә кысага өстән һәм астан ябыштырабыз. Торбаны куябыз.*

Быел андый урыннар булмас кебек, шуңа күрә оештыручылар катнашучыларның акция башында ук килүен сорый.

«Үлемсез полк» исә үзе сәгать 15.00дә старт алачак. Карл Маркс урамы буйлап китеп, «Черек күл» паркы янынннан Лобачевский урамы буенча Кремль урамыннан, 1нче Май мәйданы аша үтеп, Меңьеллык мәйданына чыгачак. Анда акциядә катнашучыларны мең кешелек «Җырлаучы Казан» хорының чыгышы, гаять зур интерактив бәйрәм программасы көтә. Маршрут ике сәгать дәвам итеп, 17.00дә тәмамланыр дип планлаштырыла.

АКЦИЯДӘ КАТНАШЫР ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ КИРӘК?

Татарстанның Иҗтимагый палата рәисе урынбасары, «Россиянең үлемсез полкы» хәрәкәтенең төбәк штабы җитәкчесе Тимур Халиков аңлатуынча, акциядә катнашыр өчен иң элек сугышта катнашкан яки тылда көч түккән якын кешегезнең фотосурәтен табарга кирәк. Аннан соң транспарант әзерләргә яки зурайтылган фотосурәтне кысага урнаштырып, очрашу урынына алып килергә. Фотосурәтләргә катгый таләпләр куелмый. Аларны фанера, каты кәгазьгә, пластмассага яки башка төрле каты әсләккә беркетергә мөмкин. Транспарант үлчәмен дә һәркем үзе хәл итә. Күпләр, гаҗәттә, А3 форматын куллана. Аларны фотосалоннарда да, өйдә дә ясарга мөмкин. Фотосалонда ясаган очракта аларның бәясе – 350 сумнан башлап 1300 сумга кадәр җитә. Әлеге хезмәтне башка салоннар да башкарырга мөмкин. Хәзерге вакытта фотосалоннарда чират булганлыктан, Тимур Халиков транспарантларны ясату хәстәрен алдан күрергә киңәш итә.

ҖӘМӘГАТЬ ТРАНСПОРТЫНДА НИНДИ ҮЗГӘРЕШЛӘР БУЛАЧАК?

Җиңү парадына әзерләнгәндә, парад һәм «Үлемсез полк» йөреше вакытында ун автобус һәм троллейбус маршрутында үзгәрешләр булачак, дип хәбәр итә Казан шәһәр Думасы аппараты. Аерым алганда, автобус һәм троллейбус маршрутындагы вакытлыча үзгәреш 3, 5, 7, 8 һәм 9 май көннәрендә булыр дип көтелә. 9 май көнне Җиңү парады һәм «Үлемсез полк» йөреше вакытында 2нче троллейбус маршруты көне буена туктатылып торачак.

9 май көнне 9.00 сәгатьтән 16.00гә кадәр 3, 5, 7, 8нче троллейбуслар йөрмәячәк. 9 майда 12.30 сәгатьтән 16.00гә кадәр Горький исемендәге мәдәният һәм ял үзәк паркыннан Карл Маркс урамына кадәр «Үлемсез полк» йөреше вакытында 22, 28, 83, 89нчы автобусларның маршруты үзгәрә. Әлеге автобуслар Вишневский урамы – Островский урамы – Татарстан урамы маршруты буенча хәрәкәт итәчәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

ТРАНСПАРАНТЛАРНЫ КАЙСЫ ФОТОСАЛОННАРДА ЯСЫЙЛАР?

1. «Мастер рекламы»
Набережная урамы, 11
Телефон: 8 (843) 239-47-97
e-mail: mreklama116@gmail.com

2. Wee-Print
Сара Садыйкова урамы, 61 (3нче кат, офис Wee-Print);
Тел. 2-672-270, 8-950-314-30-67
e-mail: wee-print@yandex.ru

3. СТАУН реклама компаниясе
Гладилов урамы, 21
Тел: +7 (843) 240-35-85
e-mail: staunr@mail.ru

4. Piart-kazan
Уң як Болак урамы, 33/1, 2нче кат
Тел: (843) 292-04-01; (843) 239-03-74
e-mail: piart-kazan@yandex.ru

5. ARTEXPRESS
Тел.: +7 (843) 518-70-07
Декабристлар урамы, 81
e-mail: pochta@artexpress.ru

6. РК «Стайл»
Аркылы Базар урамы, 57
тел: (843) 245-34-33, (843) 259-54-41
e-mail: stylekazan@mail.ru

7. «Новатор» реклама компаниясе
Скрябин урамы, 8а
Тел.: +7 (843) 267-42-01; +7 (843) 255-30-72
e-mail: reklama@musinbros.ru

8. «Полиграф» җәмгыяте
Тел.: (843) 250-36-88, т/ф.: 561-20-67
e-mail: ovvakul@mail.ru

9. РК Гамма
Чехов урамы, 9 һәм 204нче йортлар
(843) 264-50-86; (843) 264-26-73
8-987-290-36-56; 8-987-290-82-81
e-mail: gamma-k@mail.ru

10. «Печать_На_Холсте»
Павлюхин урамы, 57
Тел.: 8-917-282-69-37

11. «Объектив»
Пушкин урамы, 42
258-23-87, 264-38-16
239-22-73, 253-40-73
Зорге урамы, 95
8-987-005-33-59

12. «FRESH ART»
Ершов урамы, 61
Телефон: 8 (843) 251-55-25
e-mail: http://www.foto116.ru

«Яңа Гасыр» телеканалында Бөек Җиңү бәйрәме көн дәвамында яктыртылачак

9 Май – Бөек Җиңү көнендә Татарстан башкаласында һәм республикада барган барлык бәйрәм чаралары «Яңа Гасыр» телеканалында турыдан-туры яктыртып барылачак.

– Татар һәм рус телләрендә туры эфирдагы яңалыклардан тыш, бәйрәм көне дәвамында да безне ике зур трансляция әзерлибез: беренчесе Казан гарнизоны гаскәрләренең Меңьеллык мәйданындагы бәйрәм парады булса, икенчесе – парадтан соң оештырылган концерт программасы. Парад «Яңа Гасыр» телеканалында 9.40 сәгатьтә башлана, ә тулы беренче трансляция 13.00 сәгатькә кадәр дәвам итә, – дип сөйләде иртәнге тапшырулар иҗат берләшмәсе баш мөхәррире Леонард Дәүләтшин.

Икенче бәйрәм чараларыннан турыдан-туры трансляция 14.45 сәгатьтә башлана. Шушы вакытта «Яңа Гасыр» телеканалы «Үлемсез полк» маршын туры трансляциядә күрсәтүгә күчә. «Үлемсез полк»ның Казан урамнары буйлап атлавын һәм патриотик акциянең һәр детален, мөмкин кадәр күбрәк катнашучыларын күрсәтер өчен, «Яңа Гасыр» телеканалы быел 21 телевизион камера ярдәмендә эшләргә әзерләнә.

Меңьеллык мәйданына «Үлемсез полк» колоннасы килеп җитүгә, «Җырлы Казан» проектының концерты башланып китә. «Үлемсез полк» акциясе катнашучылары 1000нән артык профессиональ җырчыдан торган ирекле хор белән бергә караоке тәртибендә сугыш елы җырларын җырлаячак.

Бу трансляция «Яңа Гасыр» телеканалында 17.30 сәгатькә кадәр дәвам итә.

18.55 сәгатьтә – «Фашизмга каршы көрәштә башларын салган барлык корбаннарның якты истәлегенә» бер минутлык тынлык.

22.00 сәгатьтә «Яңа Гасыр» телеканалы Бөек Җиңү көне чараларының йомгаклау символына әверелгән бәйрәм салютын күрсәтә.

«Безнең тарих чит ил туристларының акылына сыймый»

ТАТАРСТАНГА КИЛ!

Гадәттә, Казанны Россиянең өченче туристлык башкаласы, диләр. Ләкин аннан тыш та республикабызда Алабуга, Болгар, Зөя утрау-шәһәрчеге, Чистай кебек популяр туристлык үзәкләре бар бит әле. Сәяхәтләр сезоны ачылган вакытта бу үзәкләрнең берсе – Болгар шәһәрен сынап карадык.

Алисә САБИРОВА

Х гасырда нигез салынган бу тарихи шәһәр заманында Явыз Иван, Екатерина II, Ибн Фадлан кебек бөек шәхесләрне сокландырган. Бүген дә ул Идел буе татарларының Ислам дине кабул итү урыны буларак изге җир санала. Экскурсоводлар 400 гектар мәйданны биләп торган тыюлыкны бер көндә генә өйрәнеп булмый, ди. Аның асылына төшенү өчен кимендә өч көн кирәк. Быел Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы туристларны «Кунакчыл Болгар» дигән программа белән каршы ала.

– 2016 елда безгә 472 мең кеше килде. Туристлар агымы ел саен 30 процентка арта. Быел Болгарга су юлы белән килүчеләр саны күбәячәк. Казан, Мәскәү, Самара шәһәрләреннән, Кама буеннан 150гә якын теплоход көтәбез, – ди Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгын үстерү эшләре буенча директор урынбасары Лилия Сафина.

Көненә 30ар туристлар төркемен кабул иткән тыюлык экскурсоводлар кытлыгын кичерми. Казанда аккредитация узган белгечләр дә үз төркемнәренә Болгар тарихы турында сөйли.

–Безгә Чабаксар, Түбән Новгород, Мәскәү, Волгоград шәһәрләреннән, Америка, Кытай, Төркия, Финляндиядән киләләр. Туристларны тарих аеруча кызыксындыра, алар биредәге архитектурага – Ак мәчеткә, зур Коръән китабына соклана, – ди музей-тыюлык методисты Люция Габдрахманова.

Татарлар белән бәйле кайбер тарихи фактлар туристларны шактый ук уйланырга да мәҗбүр итә икән.

– Безнең тарих чит ил кешесенең акылына сыймый. Кайбер туристлар: «Ни өчен сез Җәмигъ мәчете янына Успение чиркәвен эттегез?» – дип сорый. Без ике диннең янәшә булуына күнеккән инде. Ә алар моңа шакката. Германиядән килгән бер төркем турист, чирәм өстендә бөҗәк күреп, бар булганын онытты. Аларда бит бөҗәкләр юк. Болгарның бөҗәкләренә кадәр сокланалар, – дип елмая музей-агарту бүлеге мөдире Ренат Вәһапов.

Быелдан туристларны электрон туристлык-мәгълүмати үзәк каршы алачак. Биредә экскурсияләргә билетлар алып була. Болгарга килгән кешеләрнең исәбе дә шушы үзәктә санала.

Болгар – динеңне, тарихыңны тирәнтен өйрәнү өчен иң кулай җир. Биредә яшәгән бабаларыбызның фән-гыйлемгә омтылышын күреп таң каласың. Әйтик, алхимия өчен савытларны, беренчеләрдән булып, Болгарда ясый башлаганнар. Бездә Көнчыгыш медицина да алга киткән булган. Аның үрнәге буларак, бүген тыюлыкта «Табиб йорты» музее эшли.

Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүгә багышланган истәлек билгесе кунакларны Ислам билгесе булган чалма, таяк һәм кара савыты белән каршы ала. Бу билгеләр «Татарларның традицион исламы нәрсәдән гыйбарәт?» дигән сорауга җавап бирә. Чалма – татарларның суфыйчылык традицияләренә иярүләре нәтиҗәсендәге рухи ирек, таяк – тынычлык, кара савыты – мәгърифәтле ислам билгесе.

Су юлы белән килүчеләрне Болгар цивилизациясе музее каршылый. Ул бер үк вакытта вокзал функциясен дә үти. Биредә археологик казылмалар тарихын, Болгарның чәчәк ату чорын, татарларның ген формуласын, Дунай болгарлары белән Идел болгарлары тарихын белеп була.

Ак пулат – Болгар дәүләтенең танылган алты мунчасының берсе. Шәһәрдә барлыгы 20 мунча булган. Бүген бинаның нигезе генә сакланган. Аңа карамастан ике зур миче әле дә үз урынында. Бу мичләр 200 ел буена өзлексез янган. Алардан килгән пар идән аша йөргән, аяк пешмәсен өчен, шәһәр халкы мунчада агач сандалилар кияргә мәҗбүр булган.

Кара пулат, үзе кара булмаса да, тарихы шомлы. Болгарны Тамерлан яулап алган вакытта, гаиләсе белән хан бу бинага кача. Тамерлан да озак уйлап тормый, пулатны яндырырга әмер бирә. Янгында бары хан кызы Алтынчәч кенә исән кала. Тамерлан аның матурлыгына сокланып, кияүгә чакыра, ләкин кыз риза булмый. Шунда ул Алтынчәчнең Алтынбәк белән Галимбәк исемле ике энесен үтерү белән яный. Туганнарын җибәрү шарты белән, Алтынчәч Тамерланга хатын булырга ризалык бирә, энеләрен дошман җибәргәч, кыз Кара пулат тирәсендәге утлы күмерләргә сикерә.

Музей-тыюлыкта тарихи биналарның сакланып калган өлешен яңа төзелгәненнән кызыл тасма белән аералар. Бу туристларга тарихны ничек бар, шулай күрсәтү максатыннан эшләнә.

– Израильдән килгән кешеләр, безнең өчен 2000 елдан да яшьрәк булган бина яңа санала, ди. Ләкин Болгар аларны менә монысы тарихи корылма, ә менә монысы реставрациядән соң дип яшермичә күрсәтә алуы белән шаккатырды, – ди Ренат Вәһапов.

Туристларның иң яраткан урыны Ак мәчеттер, мөгаен. Ул «Кол Шәриф» мәчете архитекторы Айвар Саттаров проекты буенча төзелгән. Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев архитекторга бу эшне «Кол Шәриф»не кабатламау шарты белән тапшыра. Ләкин Айвар Саттаров Ак мәчетнең манараларын зәңгәр төскә «буяп куя». Соңыннан аны алтынсу итеп үзгәртәләр, бара торгач, ахырдан исә ул ак мәрмәрдән эшләнелә. Мәчетнең исеме дә җисеменә тәңгәл килеп тора.

– Ак мәчет Мәдинә шәһәрендәге пәйгамбәр мәчетенә охшаш. Һәр мөселман да изге җиргә бара алмый, шуңа да Мәдинәнең бер кисәге Болгарда булсын, дигән Минтимер Шәймиев. Мәчетнең ян-якларында студентлар һәм мөгаллимнәр өчен тору урыны, уку корпусы урнашкан.

Болгар республикада һөнәрчелекне үстерүче шәһәр дә әле. Тыюлыкта урнашкан осталаханәләрдә сувенирлар җитештерәләр. Болгар тирәсендә даими оештырылган кросс-биатлон бабаларыбызның сугыш коралларын кулланып карарга, тарихны яңа яктан ачарга ярдәм итә. Тарихи белем туплаганнан соң башны ял иттерү өчен дөяләр утары менә дигән урын. Биредә 80 баш дөя асрала. Алар фотога төшәргә, туристлар белән «аралашырга» ярата.

Петр I Болгарга сәяхәте вакытында биредә 77 тарихи бина сакланган булган. Екатерина патша заманында алар 44кә калган. Бүген исә Көнчыгыш мавзолей, Кече манара һәм Кара пулат кына исән.

– XVIII-XIX гасырда биредә ак таш чыгарганнар. Ни кызык, бу җирдә беркайчан да табигый ак таш булмаган. Аның урынына шәһәр калдыкларын каезлаганнар булып чыга. Болгар үз гомере бәрабәренә Россия империясен торгызырга, төзекләндерергә булышкан дигән сүз бу. Аяныч һәм сокландыргыч тарих, – ди Ренат Вәһапов.

Болгар цивилизациясе музее – 200 сум (ташлама белән – 100 сум)

Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүгә багышланган истәлек билгесе – 150 сум (ташлама белән – 70 сум)

«Табиб йорты» музее – 50 сум (ташлама белән – 30 сум)

Успение чиркәве тарихы музее – 50 сум (ташлама белән – 30 сум)

Габдрахман коесы – 30 сум (ташлама белән – 20 сум)

Калган объектларга керү ирекле.



Автор фотолары

КҮРМИ КАЛМА

Третьяков галереясы үзе килде

Автор фотолары

Казан кирмәненең «Эрмитаж-Казан» үзәгендә «Гасыр даһие...» дип аталган күргәзмә ачылды. Күргәзмәне ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Президентны Третьяков галереясының генераль директоры Зелфира Трегулова шәхсән үзе экспозиция белән таныштырып, эшләрне шәрехләп йөрде.

Расиха ФӘИЗОВА

«Гасыр даһие...» – Дәүләт Третьяков галереясы белән Татарстан Республикасы дәүләт сынлы сәнгать музееның уртак проектлар сериясеннән иң тәүгесе. Экспозиция ике музей тупланмасыннан төзелеп, тамашачы хозурына барлыгы 81 эш – 73 нәкыш һәм 8 скульптура тәкъдим ителә.

– Миңа калса, без – төп музейлар – Третьяков галереясы һәм безнең музей – шушындый күргәзмә оештырып, ил күләмендә уникаль проектны тормышка ашырдык. Иманым камил, бу яхшы фал, чөнки әлеге кыйммәтләр мәскәүлеләр һәм аның кунаклары өчен генә түгел, инде аларны казанлылар да күрә алачак, – дип белдерде Президент.

Экспозициядә рус сынлы сәнгатенең шаһ әсәрләрен дә, бик үк билгеле булмаган авторларның эшләрен дә күрергә мөмкин. Шаһ әсәрләр дигәндә, иң беренче чиратта, Третьяков галереясының даими экспозициясендә булып, музейдан бик сирәк чыгарыла торган эшләр күздә тотыла. Бу очракта ул, әлбәттә, Врубельнең «Царевна-лебедь»ы («Патша кызы – Аккош»). Әлеге әсәр күргәзмәнең афишасында ук чагылыш тапкан.

Күргәзмәгә куелган эшләр, нигездә, рус сынлы сәнгатендә XIX гасыр ахыры-XX гасыр башына караган чорны үз эченә ала. Аның рус импрессионизмына нигез салучылардан булган Михаил Врубельнең «Фауст һәм Мефистофель очышта» дип аталган декоратив панносы белән ачылып китүе дә очраклы түгел. Һәр зал зәвыклары, рухи карашлары белән бер-берсенә якын булган, билгеле бер юнәлештә иҗат иткән кылкаләм осталары берләштерә: символизм, импрессионизм, «Буби валеты» һәм «Ишәк койрыгы» берләшмәләре вәкилләренең эшләре...

– Күргәзмәне туплаганда XIX гасыр башы белән чагыштырганда яңа чорны, яңа сынлы сәнгатьне, яңа сулышны күрсәтәсе килде. Авангардны, үзгәрешләрне сиземләү ул Врубель иҗатында XIX гасыр ахырында ук башлана. Аннан рәссамнарның академизмга каршы бик актив бунтарьлыгы («Буби валеты»), яңа чорга тәңгәл булырдай яңа алым үйлап табу теләге биредә бик ачык чагыла. Реалист рәссамнардан аермалы буларак, алар хакыйкатьне тормыштан түгел, ә сәнгатьнең үзеннән, иҗат ирегеннән эзли, – ди күргәзмәнең кураторы Ольга Фурман.

Чыннан да, «Рәссам дорфа, гади, тупас, примитив булсын ул. Киләчәк лапидар стиль кулында, чөнки яңа сәнгать нечкәлекләрне яратмый, ул аннан гарык», «Сәнгать – хөрлек!» кебек шигарьләр астында Көнбатыш рәссамнары йогынтысын тоеп иҗат ителгән эшләр монда. (Михаил Ларионов «Тантана итүче муза» һ.б.) Шул ук вакытта биредә иҗатта матурлык эзләү дигән төшенчәгә дә игътибар итәргә кирәк. Һәр зал үзенең матурлык идеалын күрсәтә килә. Тагын бер кызык деталь: Ларионов тарафыннан диптих буларак иҗат ителеп тә, икесе ике тупланмада булган эшләрне – Татарстан музеендагы «Провинциальная франтиха» һәм Третьяковкадагы «Провинциальный франт»ны да шушында «очраштырып» куйган кураторлар. Моны да үзенчәлекле бер табыш дияргә кирәктер. Кыскасы, биш-алты залны бер итеп тамаша кылып йөрүче, һичшиксез, күкләр һәм су стихиясен бер иткән «Патша кызы – Аккош»тан алып, Константин Коровин (аеруча Шаляпин портреты) әсәрләрен, бернинди махсус сәнгать белеме булмаган Пиросманиның клеенкага эшләнеп, классик сәнгать канунныннан ерак торган «Гаилә компаниясе»н, Фалькның «Татар журналисты Әхмәт Рәфатов портреты»н, шулай ук Петр Кончаловский, Наталья Гончарова, Николай Рерих, Кузьма Петров-Водкин кебек рәссамнарның эшләрен генә түгел, ә Третьяковкага хас булган үзгә халәтне дә хәтеренә сеңдереп калдырыр дип ышанасы килә.

Айдар Фәйзрахмановтан – сәнгать дәресләре

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Татарстан фольклор музыкасы дәүләт ансамбле җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов район, шәһәр балаларын җыеп, сәнгать дәресләре үткәрә. Моңа кадәр дә даими рәвештә башкарылган эш бер ай элек Татарстанның Мәгариф һәм фән, Мәдәният министрлыкларының уртак проекты дәрәҗәсенә кадәр үсеп, 4 меңнән артык баланы җәлеп иткән. Айдар Фәйзрахманов белән очрашуыбызның сәбәбе нәкъ менә шушы проект турында тулырак сөйләшү иде.

– Без, кая гына барсак та, кич белән концерт куйсак, көндезен район, шәһәр балаларын җыеп, сәнгать дәресләрен үткәрәбез. Әлеге проектыбызның максаты – мәктәп балаларына эстетик тәрбия бирү, аларны татар фольклор сәнгате, халык авыз иҗаты белән таныштыру, үзебезнең җырларыбыз, бию үрнәкләребез, төрле уен коралларыбыз, милли киемнәребез хакында җиткерү. Моны без эшләмәсәк, бездән дә камилрәк итеп башка төркемнәр башкармаячак. Бу дәресләрне балалар белән берраттән өлкәннәр өчен дә, ана телебездә сөйләшмәгән татарларыбыз, башка милләт вәкилләре өчен дә бик матур итеп эшли беләбез. Монголиядәге, Кытайдагы, Эмиратлардагы балалар белән аралашуыбыз моңа дәлил булып тора. Алар җырларыбызны тыңлагач, безгә кушылып, хәрәкәтләр ясап утыра. Сәнгатьнең милләте юк, аның бары миллилеге генә бар, һәм бездә ул ярылып ята. Шушы миллилек башка милләт вәкилләре өчен дә бик якын. Әлеге сәнгать дәресләре бер сәгать дәвам итә. Мин аны үзем алып барам. Күпвакыт мәдәният, мәгариф бүлекләре башлыклары, концерттан соң килеп: «Айдар абый, сез бу яшьләрне пластилинга әйләндереп бетердегез. Безнең балаларның бер вакытта да болай кыймшанмыйча утырганнары юк иде», – диләр. Минем социаль челтәрләрдә үз аккаунтларым бар. Шушы очрашулардан соң якынча 10-15 бала дуслык тәкъдим итә. Мин моңа бик сөенәм, чөнки аудиториям үсә. Бала күңелендә үзебезнең сәнгатебезгә соклану, аның белән горурлану тудыра алабыз икән, ул беркайчан да татарлыгын җуймас дип өметләнәм. Телне, милләтне саклау юнәлешендә сәнгатьнең өлеше әйтеп бетергесез. Моңа кадәр дә шушы чараны без даими рәвештә эшләп бара идек, бервакыт Татарстан премьер-министры урынбасары – республика мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов Актаныште безне күрде дә: «Айдар абый, без моны районнарда балаларга күрсәтик әле», – диде. Мин бик теләп риза булдым. Нәтиҗәдә, бер ай элек башланган бу эшебез Татарстанның Мәгариф һәм фән, Мәдәният министрлыкларының һәм ансамблебезнең уртак проектына әйләнде. Әлегә республикабызның сигез районында булдык. Тагын Лаеш һәм Алексеевск районына барасы калды. Якын районнар сайлавыбызның сәбәбе – моңа кадәр аларда булганыбыз юк иде.

– Шушы очрашулардан кайткач, шатлану хисләрен кичерәм, дисез. Борчыган мизгелләр дә булмый калмыйдыр?

– Аралашу вакытында балаларның тарихны, аннан да бигрәк татар шагыйрьләрен белмәүләре ачыклана. Шушы проблемаларны мин сәхнәдә ачып салам һәм укытучыларга мөрәҗәгать итәм. Барган барлык районнан видеосюжетлар, фоторепортажлар төшереп алып кайттым. Әлегә бер ай эчендә 4 меңнән артык бала безнең дәресләрне күрә алды. Әйтергә кирәк, бу дәресләрне татарлар гына түгел, башка милләт кешеләре дә яратып кабул итә. Шундый концертларны әдәбият әһелләренә дә эшләү кирәк. Шушы концертларда Рөстәм Мингалимне, Мөдәррис Әгъләмовны, Илдар Юзеевны укыйм. Әйтергә кирәк, балаларда сәнгатьне кабул итү бик көчле. Без үзебезнең кирәклегебезне аңлыйбыз. Иҗат дөньясы – ләззәт бит ул. Андый вакытларда дошманың да иң якын туганыңа әйләнә. Шуңа күрә шушы матур башланып киткән проектыбызның дәвамы булыр дип өметләнеп калам.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

ХӘТЕР

tatar-inform.tatar

Туфан туган туфракта

Йолдыз ШӘРАПОВА,
Казан –
Олы Мәрәтхуҗа – Казан

«МИН – МӘРӘТХУҖА МАЛАЕ»

Кырлай, Сыркыды, Иске Кирәмәт, Күлле Киме… Татар әдипләрен дөньяга биргән шагыйранә исемле бу авыллар арасында Олы Мәрәтхуҗаның да аерым бер урыны бар. Танылган драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның туган авылы. Туфан абыйның кызы Әлфия ханым Миңнуллина һәм хатыны Нәҗибә апа Ихсанова чакыруы буенча без – бер төркем каләм әһелләре, дуслары – 1 май иртәсендә Кама Тамагы районына кузгалдык. Әлфия ханымның дулкынлануы аңлашыла – әтисенең туган нигезенә, аның вафатына биш ел тулу уңаеннан Коръән укытырга кайта бит. Юл буе бу якларның тарихы, Явыз Иван басып алганнан соң татарларга Идел буена 20 чакрым килеп авыл салырга рөхсәт булмавы турында сөйләп кайтты.

– Мин туган авылын әти кадәр яраткан, аңа дан җырлаган, аның язмышы өчен борчылган башка кешене белмим. Ул һәрвакыт: «Мин – Мәрәтхуҗа малае», – дип горурланды, – дигәч, безнең җирдәге әлеге җәннәтне тизрәк барып күрәсе килде.

Кама Тамагын чыгып олы юлдан шактый барганнан соң уң якка борылдык. Анда юл чатында ук: «Килдегезме, туганнар» дигәндәй елмаеп, Туфан абый сурәте каршы алды. Авыл үзе барып җитмичә күренми дә – уйсу җиргә урнашкан икән. Монысы да шул иманын югалтырга теләмәгән халыкның чукындыру сәясәтеннән качуы булган инде.

«ҖӘМГЫЯТЬНЕ САФЛАНДЫРЫП ТОРА ТОРГАН ЧИШМӘ БАШЫ»

Мәҗлес башланырга шактый вакыт бар иде әле. Без авыл белән танышып кайтырга булдык. Кышын 40 кеше генә яши торган бәләкәй генә авылның менә дигән айлы-манаралы таш мәчете, яңа клубы, аның янында яу кырыннан кайтмый калганнарга куелган һәйкәле бар. Кечкенә генә авылдан ил азатлыгын якларга киткән һәм кайта алмаган 61 батырның исемнәре уелган аңа. Һәйкәлнең янәгында тагын бер мәрмәр такта, анда – сугыштан кайтып та инде бакыйлыкка күчкән ветераннар исемлеге. Болар барысы да Туфан аганың туган авылына булган хөрмәте, ихтирамы, мәхәббәте турында сөйлиләр. Бу эшләрнең барысында да Туфан ага үзе башлап йөреп кенә калмаган, матди ярдәм дә күрсәткән. Туган нигезеннән ерак түгел бер чишмәне дә Туфан абый чистартып тора торган булган. Хәзер аны һәм тирәягын «Таттелеком» җитәкчесе игелекле җан Лотфулла Шәфыйгуллин егетләре матур итеп төзекләндергәннәр һәм аңа «Туфан чишмәсе» дигән исем биргәннәр. Моның өчен рәхмәт әйтергә җай да чыкты – мәҗлескә алар да кайткан иде. Бүген бөтен авыл халкы шул чишмәдән су ала. Килгән саен, Туфан абыйның ягымлы да, шул ук вакытта сынап та карый торган карашы белән очраша һәм түбәндәге юлларны күңеленә янә беркетеп куя. «Авыл – җәмгыятьне сафландырып тора торган чишмә башы ул». Төрле чишмәләрнең суын татып караган бар иде. Гадәттә, чишмә сулары тешне камаштырырлык салкын һәм ничектер каты була, ә Туфан чишмәсенең суы башка. Без аны башта кушучлап, аннары чүмечләп эчтек. Каен суы тәме дә, хәтта (динчеләр кичерсеннәр) зәмзәм сулары тәме дә бар шикелле иде анда. Гаҗәпмени, әдипләр үзләре дә чишмәдән ким түгел бит – халык җанын киптерми сугарып торалар. Туфан абый да халык бәгырен сугарып өчен аз тырышмады. Нәҗибә апа исә монда килгән саен шул чишмәдән су ташыган килен чакларын искә алмый калмыйдыр. Гомер чишмәсе, һай, тиз ага икән..

ЯШЬ ЯКТАШ – РУХТАШ

Авылның уңган апа-җиңгиләре йөгерә-йөгерә табын әзерләгән арада, без – кунаклар, Туфан абыйның музее белән танышып чыктык. Туфан аганың, аның әтисенең кул җылысын саклаган кадерле әйберләр. Менә әдип үз иткән радиоалгыч. Бигрәк тә СССР гимнын тыңларга яраткан, диделәр. Ниләр генә юк бүредә! Туфанның әтисе Габдулла агайның затлы кара савыты, агач төймәле чуты, әдипнең сыйныфташы Дания ханымның балалайкасы… Әлеге бинаны Туфан абый үзе исән чакта ук мәктәп карамагына биргән булган. Һәм ул шактый еллар башлангыч мәктәп булып торган. Әлеге мәктәптә укыган, Туфан абый кебек тел өчен борчылып йөрүче, шул хакта шигырьләр язучы бер егет белән дә таныштык без. Ул бүген Кама Тамагындагы татар гимназиясенең унынчы сыйныфында укый. Аны күрсә, Туфан абый сөенеп туя алмас, аңа багышлап берәр пьеса да язмыйча калмас иде, мөгаен. Салават Кадыйров кечкенәдән кулына каләм алып, үз хисләре белән уртаклаша башлаган егет. Бүген инде ул – күп кенә иҗади конкурс-бәйгеләрнең җиңүчесе. Ел саен диярлек якташына багышлап үткәрелгән конференциядә катнашып, призлы урыннар алып килә. Быел хәтта «Илһам» Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесендә беренчелекне яулаган. Егет киләчәктә дә каләмен читкә куярга җыенмый.

ДУСЛАР ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

Туфан аганың нигезендә бүген юан бүрәнәдән салынган алты почмаклы яңа йорт тора. Балконы да бар. Туфан ага шуннан йорт каршысындагы күлдә йөзгән каз-үрдәкләрне карап торырга яраткан. Коръән мәҗлесенә дустына әлеге йортны бүләк иткән Мөхәррәм ага Мөхәммәтҗанов та килгән иде. Мин аны якыннан беләм. Элек ул безнең Буа районындагы «Искра» колхозын җитәкләде, алдынгылар рәтенә чыгарды, хуҗалыкның абруен күтәрде. СССР Югары Советына депутат итеп тә сайладылар үзен. Туфан абый белән дә шул депутатлык гамәле таныштырган һәм дуслаштырган инде аларны. Бу дуслыкның гомере 30 елга сузылган, шуның соңгы бишесе истәлекләрдән тора. Мөхәррәм абый – иҗат кешесенең кадерен белүчеләрдән. Үзе турында зарисовка язгач, ул миңа да Паркер фирмасы каләме бүләк иткән иде. Яңа яза башлаган кызга шундый бүләк ясагач, Туфан агага 60 яшен котлап йорт җиткерүе гаҗәп түгел инде моннан соң.

Туфан аганың озак еллар Татарстан Югары Советы депутатташы, халык шагыйре Разил ага Вәлиев тә аның җир кешесе булуын үз истәлекләрендә искәртте. Бер елны алар Австриягә барганнар. Шунда, кибеттән кибеткә йөреп, Туфан ага кабак орлыгы эзләгән. «Бу ил халкы кабак үстерү белән дан тота. Шәп сорт алып кайтып утыртыйм әле», – дигән. Разил ага Туфан абыйның тагын бер хыялын җиткерде: үзенең бу өен язучыларның иҗат йорты итеп файдалануларын теләгән булган икән. Искә алу мәҗлесенә килгән һәркемдә хатирәләр шактый иде. Татарстан Язучылар берлеге исеменнән драматург, Туфан аганың шәкерте Данил Салихов, Камал театры артистлары исеменнән Әзһәр Шакиров та истәлекләре белән уртаклашкач, Туфан абый үзе дә беркая да китмәгән, шунда безнең арададыр төсле тоела башлады.

ШУШЫ ҖИРДӘН, ШУШЫ ТУФРАКТАН

Бу авылның тагын бер үзенчәлеге – аның күп кенә йортларында әдип әсәрләренә кергән геройларның прототиплары яшәгән. Язучы үз геройларын кайдандыр бармагыннан суырып тудырмаган. Алар барысы да шушы җирдән, шушы туфрактан. Менә бу яшел капкалы матур йортта яшәгән, 25 төп алмагачы булган, 92 яшенә җитеп дөнья куйган җор телле уен-көлке яраткан аксакал – койган да куйган Әлмәндәр бит инде. Явыз әҗәлне алдау, яшәү яме турындагы бу үлемсез әсәрен язганда, әдип күз уңында шул туганын тоткан һәм шундый шәп герой тудырган. «Ала карга дигән, ай, асыл кош» кунган тал тирәкле күл буеннан узганда шул хакта уйландык.

Тагын шунысын да әйтим, безгә бүгенге мәҗлестә Коръән-Кәрим аятьләрен дә «Мулла» пьесасының прототибы үзе укыды. Яшь мулла Илдус хәзрәтнең моңлы тавышы гомерләрнең бик кыска булуын һәм игелекле гамәл кылганнарның халык күңелендә озак яши алачагын Туфан ага мисалында тагын бер тапкыр исебезгә төшерде. Казаннан кадәр килгән Ильяс хәзрәт Җиһаншин да Туфан аганың рухына багышлап дога кылды.

«ҺӘРВАКЫТ ШУЛАЙ БУЛЫР»

Коръән ашының ризыклары аеруча тәмле була бит ул. Монда да табын бисмилла әйтеп пешерелгән сый-нигъмәтләрдән сыгылып тора иде. «Укыган догаларыбыз кабул булып, Туфан агабызның рухы шат булсын иде», – дигән теләк белән, кабат юлга кузгалдык. Кайтканда, кемдер: «Туфан абый зур язучы, халык күңеленә кереп калырлык күп әсәрләр язган. Ләкин ул иҗат иткән иң талантлы әсәр – аның кызы Әлфия. Әдип үзеннән соң туган телен дә, әдәбиятны, халкын яратуын кызына васыять итеп биреп калдыра алган. Әтисенең шушы васыяте аны бүген каләмдәшләрен ул туган нигезгә дога кылырга чакырды да инде. Ә бит кайбер язучыларның балалары татарча исәнләшә дә белми…» – дип куйды. Дөрес сүзгә җавап юк. Бу хакыйкатьтән соң Туфан абыйга ихтирамыбыз бермә-бер артты. Әйе, һәркем игелекле эшне үзеннән башларга тиеш. «Олуг язучыбыз Туфан Миңнуллинның исеме, аның зирәк сүзе безне бүген дә озатып бара. Бу һәрвакыт шулай булыр дип ышанам» – Рөстәм Миңнехановның музей диварына язып куелган сүзләре бу. Президент ышангач, без дә ышанабыз. Бүгенге мәҗлес ул ышанычны тагын да ныгытты.

Хөрмәтле ветеран-фронтовиклар һәм тыл хезмәтчәннәре!

9 май – барыбыз өчен дә изге көн. Бу көн – халкыбызның үлмәс рухы һәм берләшү символы да. Ул киләчәгебезне мәңгелеккә үзгәртте һәм күренмәс нык җепләр белән россиялеләрнең сугыш афәтләрен кичергән һәм тыныч тормышта гомер итүче буыннарын тоташтырды. Ветераннар үз тормышлары, каннары белән киләчәккә имин юл сузды! Без, бөек җиңүчеләр нәселе, ата-бабаларыбыз белән горурланабыз, әлеге Җиңүнең нинди корбаннар бәрабәренә яулануын һәрвакыт истә тотачакбыз!

Хөрмәтле ветераннар! Безнең арада булуыгызга, Сезгә «Рәхмәт!» дип әйтә алуыма мин бик тә шат. Күрсәткән батырлыгыгыз – бәяләп бетергесез, нәкъ менә Сез безгә тыныч тормышта яшәргә мөмкинлек бирдегез. Берничә буын Сезнең тиңдәшсез батырлык үрнәгендә тәрбияләнде.

Бәхетле тормышыбыз һәм балаларыбызның якты киләчәге өчен зур рәхмәт Сезгә. Ветеран-фронтовикларның тиңдәшсез батырлыгы, аларның хатыннары, балалары һәм әниләре, илебезне хәрабәләрдән торгызган һәммә кеше алдында баш иябез! Нәкъ менә сезнең аркада без бүген бөек илдә гомер кичерәбез.

Сезгә ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек, тормышны яратуыгызны, озак еллар тыныч һәм бәхетле гомер кичерүегезне, аяз күк йөзе теләп калам!

Тирән ихтирам белән,
РФ Дәүләт Думасы депутаты
Айрат Хәйруллин.

Бергәләп көрәшик

Татарстанда быелның 1 апреленә 9432 кеше «наркомания» диагнозы белән диспансер исәбендә тора.

Республикада 2012 елдан башлап, наркотикларга бәйле җинаятьләр кимү күзәтелә башлаган булган. Ләкин...

– Хәл кискенләште, – дип борчылып сүз башлады Казан шәһәре буенча Эчке эшләр идарәсенең наркотикларга контроль бүлеге җитәкчесе Радик Рәшитов.– Казанда быелның өч аенда наркотикларга бәйле 226 җинаять ачыкланды. Бу, узган елның шул чоры белән чагыштырганда, 65 процентка күбрәк (137 очрак теркәлгән булган).

Интернет аша наркотиклар тарату активлашкан. Казанда быелның февралендә Авиатөзелеш районында 31 яшьлек казанлы тотылган. Ул наркотиклар өчен шәһәрнең төрле җирләрендә яшертен урыннар булдырган. Сәүдә эшен интернет аша башкарган. Академик Глушко, Чыңгыз Айтматов урамнарындагы йортларның подъездларына наркотиклар кыстырып йөргән 26 яшьлек икенче бер казанлыны апрель аенда эләктергәннәр.

– Казан автоинспекторлары «Малиновка» контроль пунктында Мәскәүдә яшәүче 1992 елгы ирнең «Ауди» автомобилен тикшергәндә спорт сумкасыннан 2,5 килограмм синтетик наркотик табып ала. Нәтиҗәдә, Мәскәүдән килүче наркоканал фаш ителде. Самарадан килүче каналны да юк итүгә ирешкән идек. Быелның өч аенда наркотиклар йөртүгә кагылышлы 12 канал фаш ителеп туктатылды. Республикага наркотиклар керүне тоткарлауда безгә автоинспекторлар һәм кинологлар зур ярдәм күрсәтә, – диде Радик Рәшитов.

Кеше 30 яшьтән соң наркотикларның рәхәтлек бирүче нәрсә түгел, ә инде газаплы үлем икәнлеген ныклап аңлый.

– Наркоманнарның 60 проценты – 16-30 яшьлекләр. Иң аянычлысы шул – наркотик кулланучыларның 20 проценты – мәктәп укучылары. Яшьләр: «Наркотикны яки спайсны бер мәртәбә татып карыйм да туктыйм», – дип уйлап бик ялгыша. Туктап булмаячак, алда айлар буена каты сызлану һәм ахыр чиктә үлем көтә, – дип кисәтте Республика наркология диспансерының психология лабораториясе җитәкчесе Лилия Фәттахова.

Наркотиклар афәте һәр гаиләнең ишеген шакырга мөмкин, шунлыктан җәмәгатьчелекнең дә уяу булуы, балаларны наркотиклар кулланудан саклау зарур. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының «ышаныч» телефоны: (843) 291-20-02; 02 һәм Бердәм коткару хезмәте: 112.

Дамир БӘДРИЕВ.

БЕЛЕП ТОР!

- ✓ Балаларны яки башка кешеләрне спиртлы эчемлекләр, наркотиклар куллануга этәрсәң – биш елга кадәр төрмә;
- ✓ Чик аша наркотиклар алып керсәң, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү һәм бер миллион сум штраф каралган;
- ✓ Законсыз рәвештә үзең өчен наркотиклар сатып алсаң, ясасаң, сакласаң – өч елга кадәр төрмә;
- ✓ Наркотиклар ясаган, саклаган, йөрткән һәм башкаларга саткан очракта, сигез елга кадәр ирегеңнән мәхрүм ителәсең;
- ✓ Төркем белән яки вазифадан файдаланып наркотиклар таратсаң, сигез елдан 20 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган;
- ✓ Наркопритон оештырсаң, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм каласыңны белеп тор;
- ✓ Наркотик сыйфатындагы даруларга ялган рецепт бирсәң яки ялган рецепт ясасаң, ике елга кадәр төрмә яки 80 мең сум штраф.

Мин беләм: ул иң кирәклесе

✓ «Тупла» кертеме
Керемнәрнең ышанычлы төстә үсүе: югары процент булган счет ачыгыз

✓ «Идарә ит» кертеме
Финанслар белән ирекле рәвештә һәм җиңел идарә итегез

✓ «Уңайлы мизгелне ычкындырма» кертеме
Кыска вакыт эчендә югары процентлар

Тулырак мәгълүматны 8-800-2005-303 телефоны аша (Россия буенча шалтрату бушлай) һәм www.akbars.ru сайтында белеп була.

АК БАРС БАНК

«АК БАРС» БАНК ААҖ РФ ҮБ Генераль лицензиясе 2590 12.08.2015 ел. Реклама

Чайнворд

«Җиңү көне котлы булсын!»

1. 1945 елга кадәр Германиядә парламент урнашкан бина.
2. Советлар Союзы Герое, татар егете Газинур … .
3. Герой-шәһәр.
4. XIX гасырга кадәр рус армиясендә кече командир исеме.
5. Хәрбиләр чалбарындагы кызыл тукыма тасма.
6. Хатын-кыз очучы якташыбыз, Советлар Союзы Герое.
7. Гаскәрнең яки флотның төп көчләрдән алда бара торган өлеше.
8. Дошман территориясенә корабльдән яки очкычтан гаскәр төшү.
9. Соса шикелле һәм үзйөрешле, үзидарәле снаряд.
10. Зур Хәрби Флот.
11. Һава флоты.
12. Ату өчен кара кургаштан ясалган вак кына шарчыклар.
13. Сугышта дошман, каршы як кулына калган һәм тоткын хөкемендә йөртелгән кеше.
14. 1705-1874 елларда Россиядә ясак түләүче катлаулардан күптән түгел алынган солдат.
15. Хәрби машина.
16. Реактив минометның шаяртып-иркәләп әйтелә торган атамасы.
17. Легендар крейсер.
18. Хәрби дәрәҗә.
19. Броня белән тышланган бик көчле артиллерия корабле.

Нияз Бишбалта төзеде.

Җаваплар.
1.Рейхстаг **2.**Гафиятуллин **3.**Новороссийск **4.**Капрал **5.**Лампас **6.**Сыртланова **7.**Авангард **8.**Десант **9.**Торпеда **10.**Армада **11.**Авиация **12.**Ядра **13.**Әсир **14.**Рекрут **15.**Танк **16.**«Катюша» **17.**«Аврора» **18.**Адмирал **19.**Линкор.

Бөтен кызыклы мәгълүмат бер урында
www.shahrikazan.com

Ветераннарның иң зур хыялы – тынычлык

Җиңү көне уңаеннан Бөек Ватан сугышы ветераннарына бүләкләр тапшырылачак.

Барыбызның да күңеленә якын бәйрәмнәрнең берсе булган 9 Майга әзерлек эшләре күпкә алдан башлана. Ветераннарның саны елдан-ел кими бара, һәм аларга рухи ярдәм белән бергә, матди булышлык та күрсәтергә кирәк. Башка күп кенә предприятиеләрнеке кебек үк, «Татспиртпром»ның да шефлыкка алган ветераннары бар.

Быел алар нибары дүртәү генә калды, һәркайсы – илебез тарихында аерым сәхифә. Шуларның берсе – **Елизавета Васильевна Завгородняя.** Инде 95 яшькә җитсә дә, ул шат күңелле, рухи ныклыгын югалтмый, ялгызы яшәүне хуп күрә, чөнки берәүгә дә мәшәкать тудырырга теләми. Аның һәр тәрәзә төбе саен гөлләр чәчәк атып утыра. Ул балачактан табигатькә гашыйк, юкса сугышның бөтен авырлыгын һәм газапларын кичерә алмаган да булыр иде.

Елизавета Васильевнаны фронтка 1942 елда, өченче омтылыштан гына алалар, ике тапкыр колхоз рәисе каршы төшә. Яшь кызга авылда сугышка киткән ир-егетләр урынына бөтен авыр эшне башкарырга туры килә: арышны урак белән уралар, сугалар, бакчада бил бөгәләр. Бәрәңге, кишер, чөгендер аларны ач үлемнән коткарып кала. Ул Воронеж фронтын, Курск, Днепр, Запорожьены уза, ә Җиңү көнен Днепропетровскида дивизия штабында каршы ала.

Шатлык авазлары, кешеләрнең бәхетле йөзләре, Ватан, Җиңү белән горурлану хисләре, күз яшьләре! 1945 елның 9 мае Елизавета Васильевнаның хәтерендә әнә шулай уелып кала.

«Татспиртпром» ярдәм итә торган тагын бер ветеран – **Анна Алексеевна Федорчукова** сугышның беренче көннәрендә үк Казанның снарядлар җитештерә торган заводына эшкә керә.

– Без – 16 яшьлек кызлар – мина, граната һәм башка снарядлар өчен шартлаткычлар ясый идек. Көненә 12шәр сәгать эшлибез, ял көннәре юк, чиратлап Казан янында окоплар һәм танкка каршы озын чокырлар казыйбыз. Торак йортларның түбәләрендә патрульлек итү өчен ирекле дружиналар оештырыла, фашист бомбардировщиклары Казанга кадәр килеп җитеп, шәһәр өстенә яндыра торган бомбалар ташлый иде, – дип сөйли Анна Алексеевна.

Аның өчен сугыш – ял көннәре, отпуск, больничныйлардан башка озын-озакка сузылган биш ел, авыр шартларда 12-18 сәгатьлек хезмәт ул. Аларга тәүлегенә 600 грамм ипи бирәләр. «Минем иң зур хыялым – тынычлык», – ди ветеран.

– Дөньялар тыныч булсын, картлар һәм балалар ачлыктан үлмәсен, яшь буынга безнең җилкәгә төшкән авырлыкларны кичерергә язмасын, – дигән теләкләрен җиткерә Анна Алексеевна.

Мамадышта яшәүче **Михаил Иванов** та авыр юл уза. Балигълык яшенә җитәргә бер ел кала, 1943 елның гыйнварында аны сугышка алалар һәм хәрәкәттәге хәрби частька озаталар. Ул Ерак Көнчыгышның барлык почмакларын аркылыга-буйга гизә, «Батырлык өчен» һәм «Японияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә. 1948 елның мартында хәрби хезмәтен тәмамлап, туган ягына әйләнеп кайта. 25 яшендә өйләнә, җиде балалары дөньяга килә. Бүгенге көндә ветеранның 13 оныгы һәм 6 оныкчыгы бар.

Николай Никулин үткән юл да күпләрнекенә охшаш – аны 1942 елда 17 яшендә сугышка алалар. Башта Чиләбедә танк полкындагы махсус частьта өйрәнүләр уза, шуннан яшь сержантны Украина фронтына озаталар. Яу кырында контузия ала, Берлинга җитәрәк Шпрее елгасы буенда сугышның тәмамлануы турында белә. Тиздән аңа үзен сакчылар ротасы составында күрсәтергә туры килә. 1945 елның июлендә Потсдамда гитлерчыларга каршы илләр конференциясендә Сталин, Трумэн һәм Черчилльнең иминлеген тәэмин итә.

Быел да Җиңү көне уңаеннан әлеге ветераннар «Татспиртпром» компаниясе (алар барысы да аның структурасына кергән предприятиеләрдә эшләп лаеклы ялга чыккан) әзерләгән бүләкләр алачак. Ветераннарның һәркайсына тормышта кирәкле әйбер сайларга тырышалар, кемгәдер – телевизор, кемгәдер газ плитәсе бүләк итәләр. Моннан тыш, аларга дарулар алу өчен сертификатлар, азык-төлек җыелмалары һәм чәчәкләр тапшырачаклар.

АФИША
8-14 МАЙ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

10 май «Исәнме, улым!» (Б.Абдуразоков)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум
11 май «Бармы ришвәттән дәва?..» (З.Хәким)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
12 май «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
13 май «Васса Железнова» (М.Горький) (КДМИ студентларының диплом эше)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 100 сум
13 май «Банкрот» (Г.Камал)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум
14 май «Гөргөри кияүләре» (Т. Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

10 май «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев)
Башлана: 18.30
11 май «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 18.30
14 май «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

8 май «Муха-цокотуха» (К. Чуковский)
Башлана: 11.00, 13.00
9 май «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00
11 май «Тылсымлы кое» В.Леонтьева исемендәге Ульяновск курчак театры
Башлана: 11.00, 13.00
12 май «Тылсымлы кое»
Башлана: 11.00, 13.00
13 май «Тылсымлы кое»
Башлана: 11.00, 13.00
14 май «Не хочу, не буду!»
Башлана: 10.00
14 май «Кошкин дом» (С.Маршак)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 250-600 сум

УНИКС КОНЦЕРТЛАР ЗАЛЫ
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ, 2)

10-13 май ШТК халыкара союзы финалының дүрттән бере
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 200-450 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә). 5+

Газетабызның киләсе саны 11 майда чыга.

СПОРТ

Паспорт ал да бушлай футбол кара

17 май «Казан-Арена» стадионында Казан «Рубин»ы Мәскәүнең ЦСКА командасы белән очраша. Россия футбол премьер-лигасы матчын бушлай карау мөмкинлеге дә бар. Моның өчен нибары җанатар паспортын (FAN-ID) гына ясатырга кирәк. Шунда ук билетны да кулыңа тоттыралар.

Җанатар паспорты олыларда гына түгел, балаларда да булырга тиеш. 14 яше тулмаган балалары өчен паспортны ата-аналары тутыра ала. Документны Бауман урамындагы «Родина» кинотеатрында һәм Четаев урамы, 10нчы йорт адресы буенча алып була.

«Рубин» – ЦСКА матчы – Конфедерация Кубогы алдыннан сынау матчы. Ягъни бу көнне тамашачыларны кертү, шәһәр транспорт схемасын төзү кебек җаваплы хезмәтләрне җайга салалар. Җанатар паспортына анкетаны www.fan-id.ru сылтамасы буенча да тутырып була.

Җанатар паспорты алган кешеләр матч көнне җәмәгать транспортыннан бушка файдалана.

БАСКЕТБОЛ. 10 май көнне УНИКС Красноярск шәһәренең «Локомотив» командасы белән очраша. Плей-офф сериясенең өченче матчы «Баскет-холл» спорт залында кичке сәгать җидедә башланачак.

ВОЛЕЙБОЛ. Казан «Зенит»ы волейболчылары инде өченче тапкыр чемпионнар лигасында җиңү яулады. 30 апрель көнне алар Италиянең «Перуджа» командасын 3:0 исәбе белән җиңде. Гомумкоманда зачетыннан тыш, Вильфред Леон – иң яхшы һөҗүм итүче, Артем Вольвич – иң яхшы блок ясаучы, а Максим Михайлов MVP турниры бүләгенә ия булды.

ДЖИУ-ДЖИТСУ. 14 майда Казанның «Ак Барс» көрәш сараенда джиу-джитсу буенча Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге кубокка Бөтенроссия турниры узачак. Ярыш джиу-джитсуның Не-Ваза төре буенча үткәрелә.

Джиу-джитсу – Японияда уйлап табылган спорт төре. Ул кул сугышын хәтерләтә. Аның Не-Ваза төрендә көндәшеңне җиргә егарга, авырттыра һәм буа торган алымнар кулланырга кирәк. Турнирның ир-атлар арасында җиңүчесе хаҗ сәфәренә юллама отачак. Моның өчен спортчының мөселман кешесе булуы, моңа кадәр хаҗ сәфәре кылмавы шарт.

ХОККЕЙ. Сезон тәгәлләнгәч, «Ак Барс» хоккей клубы һөҗүмчесе Владимир Ткачев Милли хоккей лигасына китә дигән хәбәр таралган иде. Бу атнада барлык имеш-мимешләргә дә нокта куелды, клуб Ткачев белән килешүне озайтты. Яңа килешү нигезендә, 23 яшьлек хоккейчы тагын ике ел Казан командасы данын яклаячак. Бу сезонда Владимир Ткачев «Ак Барс» составында булган 73нче уенда бозга чыкты һәм 43 (17+26) очко җыйды. Хәзерге вакытта хоккейчы ил җыелмасы составында дөнья чемпионатына әзерләнә.

Абунәчегә – телевизор! Бу юлы бәхет кемгә елмаер?

Кадерле абунәчеләр, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте янә призлар уйната.

Безнең басмаларга язылган квитанцияләрнең күчерелмәләрен җибәрегез һәм призлар отыгыз. Без үзебезнең традицияләргә тугры калабыз һәм кыйммәтле приз сыйфатында кабат телевизор һәм цифрлы өч фотоаппарат уйнатабыз. Моннан тыш, 15 абунәченең сарык йоныннан эшләнгән одеял оту мөмкинлеге дә бар.

Исегезгә төшерәбез, отыш нәтиҗәләренең ничек булуына карамастан, Татарстанның һәрбер районында иң күп суммага газета-журналга язылган бер абунәчене аерым бүләк көтә.

Отышта катнашуның шарты бик гади: 2017 елның 30 июненә кадәр нәкъ менә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте чыгара торган өч басмага алты айга язылырга кирәк. Башка массакүләм мәгълүмат чараларының басмалары исәпкә алынмый. Акциядә катнашучы газета-журналларның исемлеге һәм акциянең шартлары белән тулырак итеп tatmedia.ru сайтында танышырга мөмкин.

Матбугатка язылу турындагы квитанцияләрнең күчерелмәләрен түбәндәге адрес буенча җибәрергә:

420066, Казан, Декабристлар ур., 2 яки podpiska@tatmedia.ru. Үзегезнең телефон номерын күрсәтергә һәм «Акция» дип тамгаларга онытмагыз.

Призлар 2017 елның 18 августында уйнатылачак.

Реклама, 16+
Акцияне уздыру вакыты: 2017 елның 15 маеннан 20 сентябренә кадәр.
Акция. Бүләкләр саны һәм аларны алу тәртибе турында тулырак www.tatmedia.ru сайтында.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән авазда булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1646. Гомуми тираж – 6043.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 709. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы